АЛТЫН БӘЯСЕ

Торaклы булу кул җитмәс хыялга әверелеп бара

> 15

УРЛАП ЯРАТУ

Йоласына туры китереп өйләнешкән парлар бүген ничек яши?

> 17

РИЗВАН ХӘКИМ:

«Әйтмичә, сорамыйча да җырлыйлар»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 123 (29090) | Җомга | 25 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

РИЗЫК БУЛСЫН!

БЫЕЛ БӘРӘҢГЕ УҢЫШЫ НИЧЕК?

Уңыш уртача, булганы җитә! Быел яз иртә килү сәбәпле, бәрәңгене инде казып алып, базга салып куючылар да бар. Эшләрен тәмамлаганнарның күпчелеге уңышның уртачадан яхшырак булуын әйтә. Дөрес, бакчаларында мул уңыш алучылар белән беррәттән, кәефләре кырылганнар да бар. Кыскасы, быелгы үзенчәлекле җәйгә нәтиҗәләр ясар чак җитте.

> 5

Ишетми калмагыз

Республиканың Икътисад министрлыгы илкүләм проект кысасында махсус грант алу өчен конкурс башлады. Татарстан эшмәкәрләре үз проектларын тормышка ашыру өчен 500 мең сумга кадәр грант ота ала. Әлеге грантка 25 яшькәчә булган эшмәкәрләр, шулай ук оешмасы социаль предприятиеләр реестрына кертелгән социаль эшкуарлар да өмет итә ала. Өстәмә шарт булып «Мой бизнес» үзәгендә уку тора. Грантны бизнес-проектны гамәлгә ашыру, торак булмаган бинаны арендалау һәм ремонтлау, җиһазлар сатып алу, коммуналь хезмәтләр һәм электр өчен түләү, лизинг килешүләренә һәм башкаларга тотарга мөмкин.

– Ел саен Татарстанда яшь һәм социаль эшкуарлар өчен грант күләме арта. Узган ел без 119 эшмәкәргә 47 млн сум акча бүлеп бирдек. Быел, «Кече һәм урта эшмәкәрлек» илкүләм проекты кысасында без ярдәм күләмен 2 тапкыр арттыра һәм тагын да күбрәк компанияләрне колачлый алабыз, – диде Татарстанның икътисад министры беренче урынбасары Наталья Кондратова.

Татарстанда хезмәт хакы түләү буенча бурычлар юк. Республикада бу күрсәткеч 13 ай рәттән теркәлә. Бу хакта «Реальное время» интернет басмасы яза. 2023 елның 1 августына караган мәгълүмат буенча, хезмәт хакына бәйле бурыч Идел буе федераль округының күпчелек төбәкләрендә юк. Татарстаннан тыш, Башкортстан, Мари Эл, Мордовия республикаларында, Пермь краенда һәм Оренбург, Самара, Ульяновск, Киров өлкәләрендә әҗәтләр теркәлмәгән. Гомумән алганда, Идел буе федераль округында хезмәт хакын түләү буенча әҗәт күләме 21,4 млн сумны тәшкил итә. Бурычның иң күп өлеше – 12,1 млн сум – Саратов өлкәсенә туры килә.

Бу атна азагы – киләсе атна башында Татарстанда болытлы һәм салкын һава торышы булачак. Республика Гидрометеоүзәге хәбәр итүенчә, 25 август төнендә Татарстанның көнбатышында 6–11 градус җылылык көтелә, көнчыгышта температура +1 градуска кадәр төшәчәк. Көндез +16...+21 градус булыр дип фаразлана. 26 август төнендә температура +3...+8 градуска кадәр төшәчәк. Көндез 14–19 градус җылылык һәм кыска вакытлы яңгыр көтелә. Якшәмбе исә җил һәм яңгыр булыр дип фаразлана. Көндезге температура +12...+17, төнлә +3...+8 градус булачак. Киләсе атнада да яңгырлы һава торышы сакланачак.

Татарстан халкын кыска эш атнасы көтә. 30 августта Республика һәм шәһәр көне билгеләп үтелә. Шул рәвешле 30 август эшләми торган бәйрәм көн булачак. 29 августта исә, Хезмәт кодексы нигезендә, эш көне бер сәгатькә кыскара.

Районнарда ни хәлләр?

Азнакай

Азнакайның Яңа Юл микрорайонында яңа мәчет ачылды. Рухи тәрбия бирүче Аллаһ йорты ачылу белән район башлыгы Марсель Шәйдуллин котлады. «Районыбызда 52 нче мәчет ачыла. Елдан-ел аларның саны арта. Яңа Юлда бу – икенче мәчет. Үз җирләрендә үзләре башлап, Раушания апа белән Рәшат абый Кариевлар, Физикать хәзрәт Шакиров шушы изге эшкә алынды, төзелешкә өлеш кертте. Мәчетнең исеме дә алар хөрмәтенә куелды», – диде башлык ачылыш тантанасында. Мәчет төзелешендә катнашкан кешеләргә Рәхмәт хатлары тапшырылды.
(«Маяк»)

Чирмешән

Иске Кади авылыннан Рәисә Вәлиуллина теплицасында 62 сантиметрга җиткән кыяр үстергән. Мәктәптә 36 ел математика укыткан мөгаллимә гигант яшелчәне линейка белән үлчәп, фотога да төшереп, теркәп тә куйган. «Император» сортлы, кытайныкы ул, орлыгын кызым алып кайткан иде. Тәмле, йомшак кыяр, 62 сантиметрлысын өздек инде, салатка тоттык, ике көн ашадык», – ди уңган бакчачы.
(«Безнең Чирмешән»)

Түбән Кама

Түбән Кама районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә 4500дән артык кеше эшли. 1955 мәктәпкәчә белем бирү хезмәткәре – педагоглар, 1533е югары белем алган. Өч ел эчендә балалар бакчаларына 122 яшь белгеч килгән. Тәрбиячеләрнең 35,5 проценты Түбән Кама педагогия көллиятен тәмамлаган, ә 749 кеше югары белем алган яки Тимирясов исемендәге инновация университетында һөнәри әзерлек үткән. «Киләчәктә дә уңай динамика көтәбез, чөнки хәзерге вакытта 87 педагог югары уку йортларында белем алуын дәвам итә», – ди Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү идарәсе башлыгы Светлана Андрианова.
(tat.e-nkama)

Югары Ослан

Югары Ослан үзәк хастаханәсендә седация (медицина йокысы) астында колоноскопия уңышлы үткәрелә. Бу ысулны хастаханәдә ярты ел кулланалар. Шуның да әйтергә кирәк: седация вакытында пациент авырту сизми. Операцияне яңа җиһазларда тәҗрибәле табиб башкара. Җиһазлар үзәк район хастаханәсенә «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты ярдәмендә кайтартылган. Димәк, Югары Ослан халкына колоноскопия хезмәтеннән файдалану өчен Казанга барырга кирәкми. Бу хезмәтне якынтирә районнарга да күрсәтәләр. Әйтик, күптән түгел Кайбыч районында яшәүче ике хатын-кыз колоноскопия үтә алган.

tatarstan.ru

ЭШ ҺӘМ АШ

Өч йөз мең тоннадан артык шикәр чөгендере, яшеллеккә күмелгән җәяүлеләр урамы һәм гөмбәзле чатыр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың Зәй һәм Менделеевск районнарына эш сәфәре кылды.

Зәй

Районда бөртеклеләрне узган атнада ук җыеп бетергәннәр. Бу хакта Рәискә район башлыгы Рәзиф Кәримов әйтте. Уңдырышлылык гектарыннан 26 центнер тәшкил иткән. Барлыгы 93,5 мең тонна бөртеклеләрне амбарларга төяп озатканнар. Бүген исә шикәр чөгендерен алу белән мәшгульләр. Зәйлеләр 307 мең тоннадан да күбрәк уңыш җыярга ниятли. Август ахырында шикәр заводы да эшли башларга тиеш.

Рөстәм Миңнеханов Зәйдә үсемлекчелекне үстерүне югары бәяләде. Шул ук вакытта терлекчелек тармагына игътибарны арттырырга киңәш итте.

– Сездә терлек саны кими. Моңа аерым игътибар бирергә кирәк, – диде ул. – Терлекчелек – авылда эш урыннары дигән сүз. Бу юнәлештә эшне көчәйтү зарур. Фермерлар өчен бездә төрле ярдәм чаралары гамәлдә.

Районга эш сәфәре барышында Рөстәм Миңнехановка капиталь төзекләндерелгән Фәрдиев исемендәге татар гимназиясен дә күрсәттеләр. 1 сентябрьдә уку йорты 357 укучыга ишекләрен ачачак. Гимназиядә Рәис укучылар һәм укытучылар белән дә аралашты. Зәйлеләр яңа бассейнлы да булды. Бу – райондагы икенче шундый спорт корылмасы.

– Безнең зур бассейн турындагы хыялыбыз чынга ашты, – диде Рәзиф Кәримов тантаналы чарада. – Республика җитәкчелегенә бик зур рәхмәт. Үзенчәлекле корылманы бер ел эчендә төзеп бетерделәр.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан – спорт корылмалары саны буенча ил күләмендә әйдәп баручыларның берсе. Республикада аларның саны 11,5 меңнән дә артып китә. Шул исәптән 283 бассейн бар.

Форсаттан файдаланып, Рөстәм Миңнеханов Зәйдә Бөек Ватан сугышы ветераны, Зәй ГРЭСы төзелешендә беренчеләрдән булып катнашкан Леонид Мачтаков белән дә очрашты. Йөз яшьлек ветеран Сталинград контрһөҗүмендә һәм Курск дугасындагы сугышларда катнашкан. Тыныч тормышка әйләнеп кайткач, 40 елга якын Зәй ГРЭСында эшләгән. Рәис ветеранны олуг юбилее белән тәбрик итте һәм Россия вице-премьеры Александр Новакның котлау сүзләрен җиткерде.

Менделеевск

Әлеге районга эш сәфәре «Аммоний» заводыннан башланды. Биредә Рөстәм Миңнехановны төп финанс-икътисадый күрсәткечләр белән таныштырдылар, яңа проектлар тәкъдим иттеләр. Рәис завод хезмәткәрләре белән дә аралашты. Ул шул исәптән яшь хезмәткәрләрне торак белән тәэмин итү мәсьәләсе турында сөйләде. Агымдагы елның беренче яртысына алынган мәгълүматларга караганда, предприятиедә 1390 кеше эшли, уртача хезмәт хакы 103 мең сум тәшкил итә.

Районда хәрби комиссариат бинасын да капиталь төзекләндергәннәр. Ул 1958 елда ук төзелгән булган. Яңартылган бинаны Рөстәм Миңнехановка күрсәттеләр. Рәис гражданнарны контракт буенча хәрби хезмәткә чакыру пунктын да карады.

Рөстәм Миңнеханов райондагы сәнәгать мәйданчыкларында да булды. Шул исәптән «Өй янындагы эш» проекты кысасында автомобиль чыбыклары җитештерү һәм автомобиль чыбыкларын ясау буенча җыю сәнәгате белән танышты. Компания директоры Николай Буравов сүзләренә караганда, яңа проектның төп максаты Менделеевскиның үзәк өлешендәге торак йортлар янәшәсендә урнашкан сәнәгать мәйданчыкларында укыту һәм эшләү өчен уңайлы график белән тәэмин итүдән гыйбарәт.

Менделеевскида эш кенә түгел, ял өчен дә уңайлы шартлар тудырырга тырышалар. Рөстәм Миңнеханов төзекләндерелгән Интернационалистлар җәяүле бульварыннан йөреп кайтты. «Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фонды җитәкчесе Наилә Зиннәтуллина әйтүенчә, әлеге урам шәһәрнең көньяк өлешен «йокы» районнары белән тоташтыра. Бульвар 3 нче номерлы химия-технология лицее янынннан да уза. Анда капиталь төзекләндерү эшләре башкарылган. Ул – әһәмияте ягыннан шәһәрдә икенче урындагы уку йорты. Химия-технология лицеенда барлык укучыларның 30 проценты белем ала.

Менделеевскида тагын бер иҗтимагый киңлек тә ачылды. Нинди генә әле! Хәзер районның гөмбәзле чатырлы иҗтимагый киңлеге бар. Тантаналы чарада Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Әлеге гөмбәз төзелешен бөтен шәһәребез белән кызыксынып күзәттек. Гаҗәеп төзелеш! – дип хисләре белән уртаклашты район башлыгы Радмир Беляев.

Ул республика җитәкчелегенә даими ярдәм күрсәтеп торганнары өчен рәхмәтен дә җиткерде. Рөстәм Миңнеханов исә районда күргәннәре белән уртаклашты.

– Сезне алда зур юл көтә. Менделеевскига ихтыяҗ булсын һәм көндәшлеккә сәләтле булыгыз, – диде Рәис.

МӘДӘНИ КҮПЕР

23–25 августта Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре уза. Бу уңайдан үткәрелгән чараларда ил башкаласына эш сәфәре кысасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Мәскәүдә Рөстәм Миңнеханов Россия театр сәнгате институтында (ГИТИС) да булды. Бүген ГИТИС – барлык театраль белгечлекләр һәм әзерлек дәрәҗәсе буенча белем бирүче бердәнбер вуз. Биредә барлыгы 8 факультет бар. Аларда дөньяның 27 иленнән 1800дән артык студент белем ала. ГИТИСта Татарстаннан 42 кеше укый. Моннан тыш, «Россиядә дебют» проекты кысасында да хезмәттәшлек итәләр. Ягъни иҗади төркемнәр ил төбәкләрендә чыгыш ясый. Казанда мондый спектакльләр шул исәптән Казан дәүләт яшь тамашачы театрында, Г. Тукай исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театрында да узды.

Рөстәм Миңнехановка белем бирү корпусын күрсәттеләр, институт тарихын сөйләделәр. Азактан Рәис биредә белем алучы Татарстан студентлары белән аралашты. ГИТИСны тәмамлаган якташларыбыз Мәскәү һәм республиканың әйдәп баручы театрларында эшлиләр.

ҖАНЛЫ СӨЙЛӘШҮ

Битараф кешеләр мөмкин кадәр азрак булырга тиеш. Яңа Чишмә районында узган «Бердәм Россия» көнендә партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин шулай диде. Дәүләт Советы Рәисе районда партия акциясе чараларында катнашты.

«Бердәм Россия» көнендә Яңа Чишмә районында 12 мәйданчык эшләде. Фәрит Мөхәммәтшин иң элек район башлыгы Вячеслав Козлов һәм депутатлар белән Петропавел бистәсендәге «57 нче татар ат заводы»нда булды. Завод директоры Николай Скоков хуҗалык территориясен күрсәтте. Фәрит Мөхәммәтшин ат үрчетү перспективалары, аерым алганда, токымлы атлар җитештерү белән кызыксынды. 2016 елда яңадан торгызылган татар атлары заводы Орлов юртакларын үрчетү белән шөгыльләнә. Кыска гына вакыт эчендә ат үрчетүчеләр Бөтенроссия фестивальләрендә чемпион булган дүрт ат үстерәләр. Казан, Мәскәү, Ульяновск, Ижау һәм башка ипподромнарда йөзгә якын приз яуланган. Бүген хуҗалыкта 250 баш ат асрыйлар. Ел саен 30дан артык колын туа.

Яңа Чишмә мәдәният һәм ял итү үзәк паркында Фәрит Мөхәммәтшин партиянең «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» хәйрия акциясе кысасында беренче сыйныфка баручы балаларга портфельләр тапшырды. Алар арасында махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары да бар иде. «Ел саен шундый тантаналы рәвештә, республикабызда яшәүче балаларны мәктәпкә озату традициясе барлыкка килде. Депутатлар мәктәпкә җыенырга ярдәм итүдә бик актив катнаша», – диде парламент җитәкчесе.

Ул билгеләп үткәнчә, республикада яңа мәктәпләр төзүгә һәм мәгариф оешмаларын ремонтлауга зур игътибар бирелә.

– Яңа Чишмә районы бу планда алдынгылар рәтендә. Хуҗалык субъектларының күп кенә җитәкчеләре мәктәпне, мәктәпкәчә учреждениене ремонтлауда, уку кирәк-ярагын әзерләүдә катнаша, – диде Дәүләт Советы Рәисе.

«Гражданлык сәгате» партия проекты кысасында Фәрит Мөхәммәтшин тематик квиз җиңүчеләрен бүләкләде һәм Яңа Чишмә районы укучыларына Россия гражданнары паспортын тапшырды.

«Кешегә нигез гаиләдә салына». Яңа Чишмә районы ЗАГС бүлегендә кызыл, зәңгәр якут һәм алтын туйларын билгеләп үтүче гаиләләрне котлаганда Фәрит Мөхәммәтшин шулай диде. Чара партиянең «Ныклы гаилә» проекты кысасында узды. Фәрит Мөхәммәтшин юбилярларга зур тормыш тәҗрибәсе һәм традицион гаилә кыйммәтләренә тугрылыклары өчен рәхмәтен белдерде.

– Сез – гаилә учагын саклау, балаларыгыз һәм оныкларыгыз турында кайгырту үрнәге. 50 ел бергә яшәп, тату гаилә булып, балалар тәрбияләп, оныклар үстереп, республикабызның дәрәҗәсен күтәрәсез. Шулай итеп без иң яхшы гаилә традицияләрен саклыйбыз. Мин дә хатыным белән 50 ел яшим. Аның бәясен беләм мин, – диде ул, парларны тәбрикләп.

Районның партия активы белән очрашуда Фәрит Мөхәммәтшин чарага йомгак ясады, җирлек өчен актуаль мәсьәләләрне хәл итү өчен мондый очрашуларның мөһимлеген билгеләп үтте.

– Районнарга чыгып, партия активлары, халык белән бергә төрле мәсьәләләрне уртага салып сөйләшәбез. Халык белән эшләүнең мондый формасы өметләрне аклады. Бүген дә Яңа Чишмә районында бик ачык һәм җанлы сөйләшү булды. Кешеләр мөһим сораулар белән мөрәҗәгать итә, булачак сайлаулар белән кызыксына. Бу безне сөендерә. Битараф кешеләр мөмкин кадәр азрак булырга тиеш, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Газетага языл да бүләк от

КӨТЕЛМӘГӘН БҮЛӘК

«Көтмәгән җирдән бәхет елмайды». «Ватаным Татарстан» газетасы уздырган бәйге җиңүчеләре әнә шулай ди. Әлки районыннан Ләйлә Гыйззәтуллина һәм Азнакайдан Ринат Вәлиев 2023 елның икенче яртыеллыгына газетага язылучылар арасында уйнаткан бүләгебез – медицина тикшеренүе узу өчен сертификат отты.

– Мондый сертификат – бик кирәкле әйбер, әлбәттә, – ди Әлки районының Иске Салман авылында яшәүче Ләйлә ханым. – Табибларга даими күренеп торабыз. Хәзер районда белгечләр юк. Шуңа күрә кубесенчә Казанга күренергә киләбез. Безгә бик зур файда инде бу. Шундый мөмкинлек биргәне өчен «Ватаным Татарстан»га бик зур рәхмәт. Газетаны бөтен гаиләбез белән диярлек укыйбыз. Үзем укыгач, әнигә алып барам. Ул да дәвалану, медицина турында, яшелчәләрне үстерү буенча киңәшләрне йотлыгып укый. Газетадан бик күп мәгълүмат алабыз. Республика, районнардагы танышлар килеп чыга. Алар турында да сөенеп укыйм.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Дөньяда дөреслек бар икән дип уйлап куйдым». Азнакайдан Ринат Вәлиев җиңү турында шулай ди. Узган елда Ринат абыйның бәрәңгене кузәнәктән үрчетү турында язган идек. Гомумән, аның белән гел элемтәдә торабыз без, нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәк тә, җавап бирергә әзер ул.

– Лотереяларга бик ышанып бетмим мин. Сезнең җирәбәдә откач, шундый шатландым. Дөньяда дөреслек тә бар икән дип уйлап куйдым, – дип сөйләде Ринат абый. – Казанга тикшеренүгә 19 августта улым алып барды. Шулхәтле канәгать калдым, әйтеп бетерерлек түгел. Аеруча пациентларга булган мөнәсәбәт ошады. Анда акча өчен генә түгел, чын күңелдән эшлиләр. Барлык сорауларыма җавап биреп, аңлатып, күрсәтеп җибәрделәр. Шундый ачык, аңлаешлы һәм күңелгә ятышлы булды.

Татар газеталары арасында иң ошаганы сезнеке, ди Ринат абый.

– «ВТ»ны инде ничә еллар бик яратып укыйм, көтеп алам. Хатыным да укый. Төрле темалар турында, менә бусы ничек, нәрсә турында язган, дип фикерләшәбез дә анналры утырып чәй эчәбез. Газеталар арасында сезнеке кебекләр юк. Чөнки берсендә моннан, икенчесендә тегеннән алынган. Ә сезнең үзегезнеке, аерым стиль. Тәрбия, балалар үстерү, авыл хуҗалыгы турында язмалар аеруча ошый, – диде ул.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Файдалы ризыклар

Ризык кибетләренә керсәң, тәмле исе белән дә, төсе белән дә үзенә иң нык тартып торганнары нәрсә? Кыздырылган тавык. Ысланган балык. Колбаса. Урамга чыксаң, иң җәлеп иткәне нинди ризык? Шашлык, барбекю, шаурма ише нәрсәләр. Боларның барысы да сәламәтлек өчен зарарлы, диләр. Бөтен кеше дә шулай ди. Тик бөтен кеше дә шулар алдында тыелып кала алмый, барысы да нәфес хөкеменә бирешә. Зыянлы икәнен белгән килеш сатып ала.

Ә иң файдалысы нәрсә? Әлбәттә, суган! Мең төрле сырхауга дәва. Салкын тимәсен өчен дә, буынның исән-сау булсын өчен дә. Ул хәтта венерик авырулардан да саклый икән: бер баш суган ашап куясың, бер авыру да якын килми. Тагын нәрсә файдалы? Кыяр, әлбәттә! Организмдагы бөтен шлакларны куып чыгара, йөрәк һәм кан тамырлары эшчәнлеген яхшырта, бөердәге ташларны бетерә, хәтта шикәр чиреннән дә саклый. Иң файдалы нәрсәләрнең тагы берсе – помидор. Монда витаминнарның һәм минералларның бөтен төре дә диярлек бар.

Менә ризык кибетләрендә йөргәндә, берәр җирдән шуларның исе килеп, үзләренә чакырып торамы? Юк. Алар кешене акыллы зат дип уйлап, тыныч кына үз чиратларын көтеп яталар: адәм акылы безне урап үтмәс дип уйлыйлар. Ә адәм уйлап та бирми, ул үзенә файдалы нәрсәләргә борылып та карамый. Ул исе чыккан нәрсәләргә мөкиббән китә. Ә файдалы нәрсәләр ис чыгарып ятмый.

Быел менә адәм акылы белән яшәргә уйладык. Тик файдалы нәрсәләрне генә ризык итәргә. Эшне кыштан ук башладык. Кыш – авыр вакыт, витаминнар күп тотыла торган чор. Сатып алдык инде барысын да. Кыярын да, помидорын да, кишерен дә, суганын да. Кыйммәт алар. Әмма кирәк һәм файдалы нәрсәләргә акча кызганырга ярамый. Шуннан бераз акыл керә башлады. Үзебезгә утыртырга кирәк барысын да. Күп итеп. Сатып алмаслык итеп.

Яз җитүгә, барысын да җиренә җиткереп эшләдек. Зур-зур түтәлләр хасил булды. Җирен ашлап, суын сибеп тордык. Салкыннар төшәрен алданрак белеп калсак, өсләрен каплап куйдык. Помидорларны хәтта төнгелеккә бишмәт кидереп йоклаткан чаклар да булды. Ә алар өлгергәнче көн саен диярлек кибеттән сатып алып төрле салатлар, төрле ризыклар ясадык. Файдалы ризыклар. Витаминлы.

Бер мәлне теге кыяр-помидорлар да үсеп җитте. Без аларны өзеп алып, сокланып карап тордык. Сокланмаслык та түгел бит, ел бик авыр килде, уңышка өмет өзелгән чаклар да булгалады, алай да тырыштык, төрлечә кыландырып карадык. Һәм менә... Кыяфәтләре дә ничава, тәмнәре дә искиткеч. Бераздан алар күпләп үсә башлады. Помидор түтәлләре кызарып балкып тора... Сокланып арыдык, ашап туйдык. Кышкылыкка әллә ничә банка консерв ябып, хатын-кызлар да ялкып беттеләр.

Җәй үтеп бара...

...Салат-фәләнне күптән ясаган юк инде. Бу яшелчәләрнең файдасы турында да онытттык. Үзләре дә искә төшерми. Кызарып та яшелләнеп түтәлләрдә утыра бирәләр. Хәзер инде аларга карап соклаучы да юк, өзеп тә аласы килми. Ә алар һаман җимеш бирәләр. Алар бездән өзмиләр... Нидер көтәләр...

Без дә көтәбез... Күп чирләрдән сихәт табу өчен, витаминнар җыеп калу өчен, без кыш җиткәнен көтәбез. Кибетләрдә алыр чак җиткәнен...

Әйтеп кенә бактым

Кызык ич

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Һәр нәрсәдән берәр кәмит эзләргә, гыйбрәт табарга омтылу кешенең табигатенә хастыр инде ул. Ишеткән я күргән вакыйга турында арттырып сөйләмәсәк, күңел тынычланмый, нидер җитми кебек. Хәтта фаҗигале хәлләр турында сөйләгәндә дә, кешене шаккатырырга теләп, үзебездән яңа бизәкләр өстибез, кыскасы, шыттырасы килә. Шунсыз ашау – ашау, йокы йокы булмас кебек. Мин еш кына «бер танышым» дип язам, чөнки кеше исемен әйтеп язсаң, бу аны кыен хәлгә кую булыр иде. Менә бу юлы да геройның берсен «танышым» дим. Ишле, яхшы гаиләдән ул, алты баланың алтысы да бик тәрбияле. Тик менә әлеге танышым башкалардан аерылып тора, кызык эзләргә ярата ул. Бу ярату хисе кайчак шул дәрәҗәгә җитә ки, хәтта гаиләдә килеп чыккан күңелсез, фаҗигале хәлләрне авырсынмыйча, алай гына да түгел, күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләнү хисе белән сөйләп бирә ул. Гаиләдәгеләр моңа күнеккән инде. Туганнарга берәр күңелсезлек, хәтта үлем-китем турында хәбәр җиткерәсе булса да, аңа тапшыралар, бу вазыйфаны җиренә җиткереп башкарасына ышаналар. Бер уйлаганда, аны гаеплисе дә килми. Башкалар еламыйча бер авыз сүз әйтә алмый торганда, иң йөрәк яргыч хәбәрне дә чәчми-түкми туганнарга, гаилә дусларына җиткерә әлеге танышым. Ул моңа ияләшкән, бу – аның өчен гадәти, хәтта иҗади, рухи канәгатьләнү хисләре алу дәрәҗәсендәге эш.

Һәр нәрсәдән кызык табарга омтылу бүгенге заман кешеләренә генә хас түгел. Әле Бөек Ватан сугышы тәмамлангач та, Англиядә чыгып килүче бер газета кеше үтерү, көчләү, бәла-казалар, төрле зәхмәтләргә бәйле хәбәрләр урынына бары тик күңеллеләрен генә бастыра башлаган. Һәм ике атна узгач, газетаның тиражы 15 мәртәбә кимегән, шуннан газета үз кыйбласын үзгәртергә мәҗбүр булган. Бүген телевизордан нинди тапшырулар, фильмнар карарга яраталар соң? Бу сорауны үз-үзегезгә бирсәгез, җавап табарсыз дип уйлыйм. Ә менә рәсми статистикага килгәндә, унсигез яшьтән җитмеш яшькәчә гражданнарыбызның 87 процентка якыны тискәре эчтәлектәге хәбәрләргә егылыплар китә икән. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре моңа үзләренчә аңлатма бирәләләр, без начар нәрсәләр күрсәтеп, халыкны күңелсезлекләрдән араларга, кешене ачы гыйбрәт белән тәрбияләргә омтылабыз, диләр. Кешене бит аны яман гыйбрәт белән генә түгел, яхшы үрнәк белән дә тәрбияләргә була. Менә шул безгә җитми дә инде. Телевизордан көн буе детективлар бара, экран үтереш-суеш, кыйнаулар белән тулган, кеше тискәре геройлардан да үрнәк ала башлый. Әллә ни ерак китәсе юк, Казан гимназияләренең берсендә булган атыштан соң кеше үтерүче Илназ Галәвиевкә охшарга тырышучылар булмады дисезме?

Кешенең психологиясе заманга ни дәрәҗәдә һәм ничек бәйле икәнен өйрәнеп утырганда, бер кызыклы фикергә тап булдым әле. Бары тик начарлык кына эзләү бай, тыныч илләрдә яшәүчеләргә хас, имеш. Аларга адреналин җитми икән дә, аны арттыру өчен, әчкелтем-төчкелтем мәгълүмат кирәк, имеш. Мәсәлән, галимнәр, артистлар, спортчылар, гомумән, күренекле шәхесләр турында сөйләгәндә бары тик матур сүзләр генә кызыру халыкка ошамый. Ә аларның гаилә хәлләре, ир белән хатынның бер-беренә хыянәт итүләре, аерылышкач сугыша-талаша милек бүлешүләре, кайчандыр кемнеңдер җинаять кылуы һәм төрмәдә утырып чыгуы, гомумән, кыңгыр эшләре турында мәгълүматлар күзгә чалынса, колакларыбыз тырпая, чәчләр үрә тора, хисләребез тулып ташый. Димәк, без бай, җитеш, тыныч илдә яшибез булып чыга.

КРЕДИТ ЙӨГЕН ТАРТКАНДА

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Россия Үзәк банкының төп ставканы күтәрүе бик уңайсыз вакытка туры килде. Рәсми рәвештә никадәр генә фанфаралар кагылмасын, илдә икътисадый хәл начарая. Юк, авторны кара күзлек киюдә гаепләргә ашыкмагыз. Ул рәсми мәгълүматтан алып ясый нәтиҗәләрне. Әйтик, Росстат быелның икенче кварталында икътисадый үсеш темплары 4,9 процент булды дип сөендерде бит әле. «Российская газета»дан бер цитата китерик: «надо учитывать, что год назад, во втором квартале 2022 года, ВВП упал на 4,5%, так что накопленный рост ВВП по сравнению с показателями двухлетней давности – лишь 0,4%». Гафу итегез, 0,4 процент ул статистик хата өлкәсенә карый һәм үсеш дип саналмый. Соңгы елда хәрби-сәнәгать комплексының, өч сменада эшләп, җитештерүне кискен арттыруын исәпкә алсак, гражданлык икътисады тармакларында җитештерүнең түбәнәюен аңлый алырбыз. Моны рәсми икътисад белгечләре дә раслый. «Опросы ЦБ показывают, что в августе 2023 года большинство российских предприятий сообщили о фактическом сокращении своего производства», – дип яза федераль газеталарның берсе.

Процент ставкасы күтәрелгәннән соң, җитештерү артыр дип өметләнергә ярамый. Киресенчә, реаль икътисадта проблемалар арта һәм завод-фабрикалар котылгысыз рәвештә җитештерүне киметергә мәҗбүр булалар. Моны да икътисадчылар беравыздан раслый. Җитештерүне киметүнең тагын бер сәбәбе – эшләргә кеше җитми. Ә эшче куллар яллар өчен, хезмәт хакларын арттырырга кирәк. Вәләкин җитештерүчәнлекне арттырмаган килеш түләүне үстерү котылгысыз рәвештә инфляция дигән нәрсәне кызулата. Бердән, хезмәт хакы фонды чыгымнарын продукциягә кушмый булмый, икенчедән, күбрәк алучылар күбрәк тоталар да. Безгә килеп ирешкән мәгълүматлар хәрби-сәнәгать комплексында хезмәт хакларының гадәттән тыш үсеше хакында сөйли. Халык кулланучы товарлары җитештермәүче зур бер катлауның куллану товарларына ихтыяҗы арта дигән сүз бу. Мондый «кыеклык» базарны инфляция белән турылауны таләп итә. Югыйсә дефицит пәйда булачак.

Шулай да икътисадның тамырларына кадәр үтеп керә торган проблема ул – кредитларның түләнмәве. Без бурычлар хисабына үсә торган икътисад моделендә яшибез. Бер бездә генә түгел, бар дөньяда шулай. Үсешнең бу моделен аңлау кыен түгел. Никадәр күбрәк кредит бирәсең, шуның кадәр күбрәк фатир сатыла. Сатылгач, төзелә дә инде. Автомобильләр белән дә шулай, башка халык кулланучы товарлары белән дә. Банклар кредитны каян алып бирәләр? Үзәк банктан. Үзәк банк каян ала? Акча баса. Кредитлауны арттыру өчен, күбрәк акча басарга туры килә. Акча басу темплары җитештерү темпларын узып киткәнлектән, җитештерүчеләр бәяне күтәрәләр. Бәя күтәрүгә тагын бер нәрсә этәрә. Җитештерүчеләр дә кредит алып ишәйтә продукцияне. Комплектлаучы детальләр һәм чимал завод складына үзләре килеп ятмый. Алдан түлисең, түләгәч кенә логистика дигән катлаулы челтәр аша килеп җитә. Чимал җитештерүчеләр дә кредит ала. Кредитлар процентлы. Процентлы кредитны түләү өчен җитештерүне арттырырга кирәк, яисә бәяне. Соңгысын арттыру җиңелрәк булганга күрә, шунысы арта да инде. Кыйммәткә алырга теләмәсәләр, дефицит ясыйсың. Складта товар ашарга сорамый. Соңгы ике-өч елда без төзелеш товарларына бәяләр ничек үскәнен күрдек инде. Бәяләр үсү кешеләрне кредит алырга мәҗбүр итә. Бердән, бүген алмасаң, иртәгә кыйммәтрәк булачак. Икенчедән, кредит алмасаң, төзи алмыйсың. Материалларга бәяләр шундый: хезмәт хакы гына җитәрлек түгел. Адәм балаларының җелеген суыра торган механизм якынча шулай туа. Тышкы яктан караганда, барысы

vk.com

да ал да гөл кебек. Җитештерү арта, торак төзелеше арта, кешеләр яңа автомобильләр, фатирлар ала. Бүген үк түлисе булмагач, иллюзия туа. Шуның нәтиҗәсендә фикерләү сәләте кими һәм югала. Без телефон мошенникларының кешеләрне бик җиңел гипнозлап, һәлакәтле адымнарга этәрүен күзәтәбез бит әле. Кредитоманлык нәтиҗәсе бу. Кредит алып, барлык проблемаларны да хәл итеп була дип уйлау мошенниклар янавыннан да шул ук ысул белән котылырга этәрә. Бурыч җыю чире кеше психикасының какшавына китерә.

Бар нәрсәнең дә чиге булган шикелле бурычка яшәүнең дә ахыры бар. Чамадан тыш кредитлау әҗәтләрне түли алмауга китерә. Россия бүген үсешенең шул этабына кереп бара. Күп кенә экспертлар инде килеп туган вазгыятьне «коточкыч» дип атый. Суд приставларының федераль хезмәте, банк кредитлары буенча түли алмаучылар саны 18 миллионга якынлаша, дип белдерә. Төгәлрәк санны әйтсәк, 17,7 миллион кеше инде «яфрак асты»нда. Автор бурыч түли алмаучыларның революциягә кадәрге татарча атамасын кулланды. Татар әдәби теленә «яфрак асты» термины банкирлар жаргоныннан килеп кергәндер, мөгаен. Русча «яма», «долговая яма» дигән сүз кулланыла күбрәк. Менә шул «яфрак асты»нда яисә упкында 18 миллионга якын кеше яши. Бу – эш яшендәгеләрнең 23,3 проценты. 75,6 миллион эш яшендәге кешенең тагын күпмесе «яфрак асты»на керергә җыена – безгә мәгълүм түгел. Үсеш темпларын карасак, тагын берничә елдан ил белән «яма»да булачакбыз. 2020 елда бурыч түли алмаучылар саны 9 миллион, ягъни хәзергедән ике тапкыр кимрәк булган. 2021 елда – 12 миллион, 2022дә – 14,4 миллион. Үзәк банк төп ставканы күтәргәч, банкротлар санының тизрәк үсәчәген чамалау өчен «матанализ»дан имтихан биргән булуың кирәкми.

Вазгыятьнең мондый темплар белән начараюы рәсми даирәләрне дә уйга сала башлады. Россия Президенты ярдәмчесе Максим Орешкин бу уңайдан борчылу белдерде. Үзәк банкның банк көйләве һәм аналитика департаменты директоры Александр Данилов халыкның чамасыз кредит җыюы хәвефләнү уятуын әйтте.

Эшнең кыен ягы шунда: хөкүмәт һәм рәсми финанс хакимиятләре кредитлау хисабына үсеш моделеннән чыга алмыйлар. Кредитлауны туктату икътисадның җимерелүен вәгъдә итә. Дәвам итү дә һәлакәткә илтә, билгеле, әмма катастрофа ерак офыкта булып тоела. Төп ставканы күтәрү хисабына инфляцияне авызлыклыйбыз, кредитлауны киметәбез дигән ялгыш адым атларга туры килә. Башка илләр тәҗрибәсе бу юлның да һәлакәтле икәнен раслый. Әмма катастрофаның артка күчүе алдаучан тынычлык бирә. «Киләчәктә я патша үлә, я ишәк, я мин», – дигән Хуҗа Насретдин фәлсәфәсе белән яшәргә туры килә.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

РИЗЫК БУЛСЫН!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

dreamstime.com

Өлгергәнме?

Узган атнада республика халкы акрынлап бәрәңге уңышы җыюга керешә. Кемдер балаларының укулары башланганчы эшен бетереп куярга ашыкса, кемдер, өлгергән булгач, уңышны һаман да җир астында яткыруны яхшысынмый. Дөрес, араларында «күршедән калмыйк» дип тырышучылар да юк түгел. Әле иртәрәк дип, сентябрьне, көннәрнең суытып җибәргәнен көтүчеләр дә күп.

Буада яшәүче һәвәскәр бакчачы Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов бәрәңгене апрель башында ук утыртып гаҗәпләндергән иде. Шуңа күрә уңышны да беренчеләрдән булып җыеп алды ул.

– Әлегә минем өчен уңышлы сорт – «Ажур». Ул корылыкка да чыдам, кышны да яхшы чыга. Бозылганы да, үреп караганы да юк. Базда кышлап, тәме дә яңа бәрәңгенеке сыман кала. Быел бәрәңге мәйданым 20шәр метрлы 20 бураздна иде. Шуның күпчелек өлешен «Ажур» алып торды. Уңышы да шәп. Бер метр буразна 5,2 килограмм уңыш бирде. Соңгы елларда бер бәрәңге зурлыгы 360 граммга җиткән булса, быелгы рекорд 500 грамм булды. Бераз «Лидер» сортын да утырттым. Ул да – яхшы сорт, «Ажур»дан 3–4 көн алданрак өлгерә, тик дым ярата, – диде ул.

Социаль челтәрләрдә актив бакчачы башка кешеләр белән дә аралашып, тәҗрибәләре белән уртаклашып тора. Аның әйтүенчә, быел «икенче икмәк» күпчелек кешедә уртача уңыш биргән.

– Быел яз иртә килгәнлектән, күпләр бәрәңгене иртә утыртты. Һәм андыйлар отты да, чөнки кырауларга кадәр тамырларын яхшылап җәеп калды. Шуңа күрә суыклар зур зыян сала алмады. Минем үземнекеләрне дә тулысынча кырау сукты бит, ләкин иртә утырткач, җиңел генә тернәкләнеп киттеләр. Кешеләр әйтүенчә, уңыш төрле җирдә төрлечә. Моның сәбәпләре дә төрле. Симәнәсе алыштырылмаган, яңгыр сирәк эләккән якларда уңыш та куандырырлык түгел. Җәй кызу булганлыктан, кайберәүләрнең бәрәңгеләре җир астында үрә дә башлады. Ләкин безнең якларда уңыш күпчелек кешедә начар түгел. Яңгырлар да булды, – диде Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов.

Бәрәңгене кайчан алу яхшырак соң? Аның өлгергәнлеген каян белергә? Оста бакчачы аның берничә ысулын әйтте.

– Бәрәңге 73 көндә өлгерә. Шуңа күрә кыраулардан соң утыртучыларныкының да өлгерергә вакыты бар. Көз озын бит. Сабаклары яшел булса да, йолкып карагач, бәрәңгесе туфракта кала икән, өлгергәнлеккә ne аңлата. Ияреп чыкса, үсәргә вакыт бар дигән сүз. Безнең үзебез утырта торган сортның сабаклары яшел булса да, уңышын җыеп алдык инде. Мондый бәрәңгене җир астында тотуның мәгънәсе юк, – дип аңлатты ул.

Тәҗрибәле фермер Минталип Миннеханов та бу мәсьәләгә карата үз киңәшләрен бирде. Бакчаның 80 проценты саргайса, бәрәңге сабагын чабып алырга кирәк, ди ул. Казыганчы 10 көнләп тотсагыз яхшы, чөнки сабагыннан өзелгән бәрәңге бу вакыт эчендә ныгый, инфекцияләр дә юкка чыга.

– Өлгерешкә килгәндә, анысы сортка бәйле, – ди ул. – Хәтта 45 көндә ашарлык булып өлгерә торган бәрәңге бар. Ләкин ул бик тәмле булмый. Кышка саклар өчен уртача һәм соң өлгерә торган сортларны сайлыйлар. Май башында утыртган бәрәңгеләр алырлык булып өлгерде инде хәзер.

Бары җитә

Мамадыш районының Баскан авылында да уңыш җыеп алучылар бар.

– Без бәрәңгене 30 апрельдә утырттык. Җәй бик эссе булды, безнең якларда яңгыр 2–3 тапкыр гына яуды. Шуңа күрә булдыра алганча су сиптек. 19 августта бәрәңгенең эшен тәмамлап куйдык та инде. Гомумән алганда, уңыш әйбәт булды, су сипкән җирдә тагын да яхшырак, – диде Гөлназ Гыйләҗева.

Ә менә кукмаралылар эш башлар өчен сентябрь урталарын көтә.

– Бездә бакча казыган кеше юк әле. Иртәрәк дип уйлыйбыз, – диде Бакчасарай авылыннан Чулпан Һадиева. – Кирәк кадәр генә ашарга алгалыйлар. Үзебез бер тапкыр гына алып карадык. Эре булса да, өлгермәгән иде, тәмле булмады. Әле безнең бәрәңге сабаклары ямь-яшел. Елдагыча, сентябрь урталары җитмичә алмабыз, дип планлаштырып торабыз.

Соңгы ике елда күпчелек кеше бәрәңгенең начар үсеннән, уңышның вак булуыннан зарланган иде. Гомумән алганда, быел халык белән аралашканнан соң, хәлләр начар түгел, дигән нәтиҗәгә килдек. Хәер, ара-тирә начар уңыш алуларын да әйттеләр.

– Балык Бистәсе районында яшәүче әти-әниләрнең бәрәңгесе начар булды, – диде Алисә Шәрәфиева. – 4 капчык утырткан булганнар. Ашар өчен 8 капчык уңыш җыеп алганнар. Орлыклык та бераз гына җыелган. Әни, су сипкән җирләрне генә сөендерде, калган урыннарда бик начар, диде.

Ә менә Азнакай якларында яшәүчеләр быел яхшы уңыш алырга өметләнә.

– Без ике ел рәттән бәрәңге уңышын ала алмадык. Бик вак булды. Быел бәрәңгене бер бакчага май урталарында, икенчесенә июнь урталарында утырттык. Аратирә ашар өчен генә алып керәбез. Уңыш начар булмаска охшаган. Беренче бакчадагы бәрәңгеләр озак тишелә алмыйча ятты, аларына иң кирәк вакытта яңгыр да аз эләкте. Ә менә икенче бакчага утырткан бәрәңгегә июль яңгырларының шифасы зур булды. Алары июль ахыры – август башында да ап-ак чәчәктә утырды әле. Үсәргә вакыт бар, өлгерерләр, дип уйлыйбыз, – диде Беренче Май авылыннан Зәлифә Мостафина.

Бәрәңгене ничек дөрес сакларга?

Иң яхшы температура – +2+3 градус.

Иң яхшы урын – коры, салкынча, караңгы һәм яңгыр, суык үтми торган баз яки подвал.



Шәһәр фатирларында исә аны караңгы, салкынча бүлмәдә, җылытылган балкон яки лоджиядә сакларга киңәш ителә.

Һава йөреп торсын өчен агач рәшәткәле поддоннар куллану яхшы.

Шулай ук бәрәңгене табигый тукымадан тегелгән капчыкларда да сакларга мөмкин.

СЕЗДӘ УҢЫШ НИЧЕК?

Гөлназ ШӘЙДУЛЛОВА (Балык Бистәсе):
– Без бәрәңгене 1 майда утырткан идек. Шуннан соң суыклар һәм корылык китте. Бәрәңге бер ай җир астында тишелеп чыга алмыйча ятты. Аннан соң яхшы гына күтәрелеп китте. Узган атнада алдык та, чөнки сабаклары кибеп, корып беткән иде. Бер төптән бик аз, 3–4 бәрәңге чыкты. Ләкин алар эре булды.

Рамил ХАННАНОВ (Казан):
– Без алдык та базга да салып куйдык. Сабак кипте, бәрәңгеләр йомшый, пешә. Вакыт сузудан мәгънә юк. Узган ел да шулай 10 августта алган идек. Бәрәңгебез бик яхшы сакланды. Иртә, уртача өлгерә торган сортларның алырга вакыты җитте инде. Хәзер элекке заман түгел, һава торышы үзгә, барлык яшелчә, җиләк-җимеш иртә өлгерә.

Ризәлә ФӘЙЗУЛЛИНА (Арча):
– 30 апрельдә җиде-сигез чиләк тирәсе бәрәңге утырткан идек. Мул уңыш алдык, бәрәңгеләребез бик эре булды. Ике капчыкны симәнәгә дип калдырдык. Җәй коры булды бит, шуңа күрә суны үзебез сипкәләдек. Сортларга килгәндә, «Самбо» дигәненең уңышы аеруча шәп булды. Моннан тыш, «Люкс», «Коломба», «Горняк» дигәннәре дә начар түгел. Соңгы берничә ел гел шулай иртә утыртып, иртә ала башладык. Узган ел 13 августта ук бакча эшен бетереп куйган булганбыз.

Рәйхана ШАКИРОВА (Алабуга районы Көек авылы):
– Авылдашлар алгалый башлады инде. Яңа җиргә утыртканнарның уңышлары начар түгел. Без сабыр итәбез әле, тишелүе дә соң булды. Бик мул уңыш булыр дип әйтеп булмас. Күпме булса да, җитәр, аның өчен борчылмыйм. Иң мөһиме – саулык белән ашарга язсын. Киләсе елга утыртырга җитсә, мин бик риза.

ЭНЕРГЕТИКА ТАТАРСТАННЫКЫ БУЛДЫ!

Куркынычсызлык, иң заманча җиһазлар, яңа техник мөмкинлекләр һәм берниндди персоналсыз эшләү. Казанның Азино микрорайонында әнә шундый цифрлы яңа подстанция ачылды. 100 меңгә якын кешене, берничә дистә поликлиника һәм хастаханәне, мәктәп һәм балалар бакчаларын электр белән тәэмин итәчәк объектны республика энергетикасында ел вакыйгасы буларак бәялиләр. Яңа подстанцияне Татарстанныкы дип әйтергә дә була. Чөнки андагы җиһазлар тулысынча үзебездә җитештерелгән.

Кичә белән бүген очрашкач

Яңа энергетика объекты 110 кВ көчәнешле «Азино» подстанциясен алыштырачак. 1987 елда сафка баскан подстанция дә үз заманы өчен алдынгы саналган. Тик тормыш бер урында гына тормый. Микрорайон үсә, зурая һәм шуның белән таләпләр дә үзгәрә. Иске трансформаторны тагын да көчлерәккә алыштыру сорала.

Подстанцияне ачу тантанасында моны Татарстанның Премьер-министры Алексей Песошин да ассызыклады.

– Яңа энергетика объекты 35 ел файдалануда булган һәм ул вакытта әле яңа гына үсеш ала башлаган Азино микрорайонын энергия белән тәэмин итүче иске подстанцияне алыштыру өчен булдырылды. Аны файдалануга тапшыру микрорайонны электр белән тәэмин итү сыйфатын яхшыртып, республиканың энергетика куркынычсызлыгын ныгытуга хезмәт итәчәк. Бүген икътисад үсеше цифрлы трансформациядән башка мөмкин түгел, – диде ул.

Безгә «Казан электр челтәрләре»ндә 1979 еллардан алып эшләгән Хатыйм Дәүләтшин белән сөйләшеп алырга насыйп булды. Ул елларны сагынып искә алса да, хәзергесенә ихластан сокланучын белдерде ветеран.

– «Азино» подстанциясендә эшли башлаган елларда бөтен җирдә буш ялан иде. Шуннан соң күп вакыт узды инде. 40 ел эшләү дәверендә бәйрәмнәре дә, аварияләре дә, проблемалары да булды. Ләкин без авырлыкларны һәрвакыт җиңеп чыктык. Бүген яңа подстанциягә экскурсия оештырдылар. Мин шаккатып карап йөрдем. Барысы да яңа, матур, заманча. Энергетика күз алдында үсә. Без эшләгән чор белән бүгенгене чагыштырып та булмый. Җир белән күк арасы. Хезмәттәшләремә уңышлар һәм авариясез эшләүләрен телим, – диде Хатыйм Дәүләтшин.

Пандемия вакытында башланган төзелеш

Яңа подстанциянең проектын төзегәндә энергетиклар заманча ысул файдаланган: куәте шул ук калса да, яңасында токны көчәйтүче трансформатор кулланыла. Бу исә моңа кадәр булган күпкатлы йортларны да, яңаларын да электр энергиясе белән токкарлыксыз тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Проектны «УК КЭР-Холдинг» җәмгыяте тормышка ашырган. Проект җитәкчесе Михаил Чубуков әйтүенчә, иң мөһиме – бер подстанциядән икенчесенә күчүне микрорайон халкы сизми дә калган.

– Әлеге подстанция шәһәрдә урнашкан, шуңа күрә аны билгеле бер шартларга туры китерергә кирәк иде. Аннан соң, сафка баса торган объект янында гына искесе эшләвен дә истә тоттык. Төзелеш 2020 елда – пандемия вакытында башланды. Бу шулай ук билгеле бер дәрәҗәдә авырлык тудырды. Боларга соңрак санкцияләр дә килеп кушылды. Ләкин, авырлыкларга карамастан, барысын да вакытында эшләп төгәлләдек, – диде ул.

Подстанциянең тулысынча автоматлаштырылган идарә итү системасында булуы да – аның төп үзенчәлекләреннән берсе. Биредә кешеләр эшләми, диспетчер барлык кирәкле эшләрне читтән торып – 15 километр ераклыктагы «Казан электр челтәрләре» бинасыннан башкара. Гомумән, яңа ачылган объектның уникаль, киләчәк энергетикасының ышанычлы үрнәге булуына кат-кат басым ясалды. Әйтик, подстанцияне төзегәндә үк цифрлы модель кулланылган. Бу да – яңалыкка тагын бер адым дигән сүз.

> **Цифрлаштыру ул – энергетика. Ул күп куәт сорый. Башкача була да алмый: сез цифрлаштыруны энергетикасыз башкарып карагыз! Безгә бүген куәтне арттырырга кирәк – замана таләбе әнә шундый, – диде тантаналы ачылыш вакытында «Сетевая компания» җәмгыяте генераль директоры Илшат Фәрдиев.**

– Быел «Казан электр челтәрләре»нең – 80, Казан энергетика университетының 55 еллык юбилее. Бу – зур горурлык. Һәм бүген менә шундый объект ачылышында катнашабыз. Мондагы җиһазларның барысы да Россиядә җитештерелгән, үзебезнең проектчы һәм белгечләрнең куллары белән эшләнгән. Ягъни энергетика Татарстанныкы булды!

Камилләшү

110 кВ көчәнешле «Азино» подстанциясе – Казанда ябык типтагы икенче цифрлы подстанция. Биредә барлык җиһазлар да бинаның эченә урнаштырылган. Бу, бер яктан, матур, җыйнак, халык өчен куркынычсыз һәм тавышсыз булса, икенче яктан, экологиягә зыян китерми. Билгеле, мәйданны да азрак ала.

– Моны тарихи вакыйга дип кабул итәргә була. Бу ябык типтагы цифрлы икенче подстанция булса да, камилләге буенча беренче урында тора, – диде «Казан электр челтәрләре»нең баш инженеры Сиринат Шаһиев. – Объектның тагын бер үзенчәлеге: Вознесенский тракты төзелеше кысасында подстанция территориясендә 110 кВ көчәнешле бүлеп бирү пункты төзелде.

Шул ук вакытта подстанциягә Киндери – Үзәк кабельле һава линиясен кертү мөмкинлеге булдырылган. Энергетиклар, саклау зонасының чикләрен киметү һәм яңа трасса төзелешенә коридор бирү өчен, 5 км югары вольтлы артерияне җир астына «яшергәннәр».

Исеме һәм җисеме

Яңа цифрлы подстанция 1976–1994 елларда Мәскәү энергетика институтының Казан филиалы директоры, Татарстан энергетикасына үзеннән зур өлеш керткән Форель Тинчурин исемен йөртәчәк. Подстанцияне ачу тантанасында бина фасадына күренекле энергетик хөрмәтенә мемориаль такта урнаштырдылар. Аның авторы – скульптор, Татарстанның рәссамнар берлеге рәисе урынбасары Фәнил Вәлиуллин.

Укучылары һәм хезмәттәшләре Форель Тинчуринны зур хөрмәт белән искә алып, аның үзеннән соң чын профессионаллар калдырган шәхес булуын әйтте.

– Үз вакытында Форель Закирович барыбызга да зур тәрбия бирде, – дип искә алды үзенең остазын Илшат Фәрдиев. – Ул киң күңелле, акыллы, тәрбияле һәм зыялы кеше иде. Аудиториягә аягын сөртеп керә, исәнләшә иде. Безгә, студентларга хөрмәт белән карады. Форель Закирович безнең һәрберебезне танып белә иде. Ашханәгә кергәч тә, безнең белән бер чиратка басты. Һәм берәр студентның акчасы җитеп бетмәсә: «Минем хисапка язгыз», – дип әйтә иде. Чын җитәкченең нинди булырга тиешлеген без әле хәзер генә аңлыйбыз. Ул вакытта без боларны белмәдек. Кыскасы, яңа подстанциягә Форель Тинчурин исемен бирергә уйлагач, безнең инициативаны бертавыштан хупладылар. Барыбыз өчен дә кадерле һәм яхшы күңелле кешенең исемен мәңгеләштерү бик кирәк иде. Аның якты истәлеге безнең күңелләрдә озак сакланачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА

1 сентябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Гөлгенә ШИҺАПОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

«ВТ» архивыннан

Бездә дә ярминкә узачакмы?

Мин «Салават Күпере» микрорайонында яшим. Быел бездә дә авыл хуҗалыгы ярминкәләре узачак дигәннәр иде. Инде сентябрь җитте – аның өчен урын әзерләгәннәре күренми. Ул ярминкәне бездә оештырмаска булдылармы икән әллә? Булса, кая барасы була икән?

Кәшифә ФӘХРЕТДИНОВА. Казан

Казан шәһәре мэриясеннән:
– Вәгъдә ителгәнчә, быел «Салават Күпере» микрорайонында да авыл хуҗалыгы ярминкәләре гөрләячәк. Сәүдә нокталары «Осиново» бистәсендәге «Радужный» сәүдә үзәге каршында парковкада урнашачак. Быел Казанда барлыгы 15 мәйданда авыл хуҗалыгы ярминкәләре эшләячәк.

Ялда чакта «больничный» түләнәме?

Бер атна элек отпускыга чыктым. Көтмәгәндә авырып киттем, операция ясадылар. «Больничный» ачарга туры килде. Отпуск вакытында ачылган «больничный» өчен миңа акча түләнерме икән?

Фәрия ИБРАҺИМОВА. Апас

Россия Социаль фондының Татарстан буенча идарәсе:
– Әгәр кеше еллык ялы вакытында авырып китсә яки имгәнсә, аңа «больничный» түләнергә тиеш. Эш стажы 8 ел һәм аннан да артыграк булганда ул хезмәт хакының – 100 проценты, эш стажы 5–8 ел булганда – 80 проценты, 5 елдан да кимрәк булганда, 60 проценты күләмендә түләнә.

Чит илгә чыга аламмы?

Моңарчы алиментны вакытында түләп барган идем. Соңгы айларда эшсез калдым. Үземнең күпме бурычым барлыкны каян белеп була? Ничә сум бурыч булса, чит илгә чыгармыйлар икән?

Наил КАШАПОВ. Чаллы

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе:
– Бурычлар хакында Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе сайтының төп битендә һәм Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең мобиль кушымтасы аша белергә була. Бурычы бармы-юкмы икәнлеген белү өчен, гражданинга сайтка кергәч, фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм туган көнен язарга кирәк. Әҗәте булган очракта аның хакында бөтен мәгълүмат күрсәтеләчәк. «Банк данных исполнительных производств» сервисыннан файдаланып, бурычны түләү өчен квитанцияне чыгартып алырга һәм теләсә нинди уңайлы ысул белән, шул исәптән сайт аша да, аны түләргә мөмкин.

Йортны ничек үз исемеңә күчерергә?

Безнең авылдагы йорт, җир, пай җирләре әни исемендә. Ул аларны миңа калдырырга дип васыятьнамә язган. Әни үзе исән-сау. Аларны хәзер үк минем исемгә күчерик, ди. Эшне нидән башларга икән? Васыятьнамә язылган булгач, хәзер моны, гомумән, эшләп буламы?

Рифат ГАРИФУЛЛИН. Арча

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:
– Бу очракта иң җиңел һәм гади ысул – милекне бүләк итеп бирү килешүе төзү. Моны үзегез дә, яки юрист, нотариус аша да эшли аласыз. Ул килешүне нотариуска барып төзесәгез яхшырак, билгеле. Ул сезгә нинди документлар җыярга кирәклеген дә аңлатачак. Россия Салым кодексының 217 маддәсендәге 18.1 пунктның 1 абзацы нигезендә милекне якын туганыңа бүләк итеп биргән очракта салым түләргә кирәкми.

Декларация тапшырасымы?

Күптән түгел генә фатир алыштырдык. Бер ел эчендә фатир сатып, яңасын алсаң, декларация тапшырасы түгел, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

Алсу САЛИХОВА. Казан

Рәмзия МӨХЕТДИНОВА, Татарстан буенча 6 нчы номерлы районара салым инспекциясенең баш дәүләт салым инспекторы:
– Билгеле булганча, биш елдан кимрәк вакыт дәвамында үз милкең булып торган мөлкәт өчен декларация тапшырырга кирәк. Күптән түгел бу юнәлештә яңа закон гамәлгә керде. Ике яки аннан да күбрәк балалы гаилә, фатирын сатып, бер ел эчендә зуррак яңа фатир сатып алып, торак шартларын яхшырткан булса, декларация тапшырмый. Алардан аңлатма язуы гына кирәк булачак. Әмма бу мөмкинлектән файдалану өчен, гаиләнең бик күп таләпләр буенча туры килүе кирәк. Бу очракта фатир мәйданы да, гаиләнең башка милке булу-булмау да исәпкә алына.

Укучы фикере

«ОЧТЫ, ОЧТЫ...» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР

Никадәр кеше нужа күрә шушы микрозаемнар белән. Нигә бөтенләй ябып бетермиләр икән аларны, Ходаем?!

Нурзилә ШӘЙМӘРДАНОВА

* * *

Кредит алганда нигә камера кулланмыйлар соң? Монда микрозаем бирүчеләрне игәүләргә кирәк. Күрергә язмасын!

Ләлә ӘХМӘДИЕВА

«ҮТКӘННӘР САГЫНДЫРА(МЫ)?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Салават Салават инде, кабатланмас. Искиткеч, халыкның мәхәббәтен яулап, 35 ел шул мәхәббәтне сүндермичә саклап тора алучы бердәнбер артист та әле ул. Яраттык, яратабыз, яратачакбыз. 40 нчы концертына да килергә насыйп булсын, Раббым!

Фәния ВАҺАПОВА-ИЗМАЙЛОВА

«СӘЕР ЕЛ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР

Безне бик авыр еллар, хәтта гасырлар көтә. Климат үзгәрә һәм моңа кешеләр гаепле. Сазлыкларны корытып, урманнарны, әрәмәләрне һәм болыннарны бетердек. Аллаһы Тәгалә һава торышын үсемлекләр ихтыяҗына бәйләп яраткан. Ә без бик күп төрле үсемлекләрне бетердек. Шуңа күрә хәзер хаос башланды һәм ул көчәячәк кенә.

Рәшит ХАННАНОВ

* * *

Флера апа, сезнең язмалар үзләре дә җиләк кебек, укырга тәмле. «Татарстан яшьләре»нең иң көчле, яратып укыла торган мәкаләләр белән сөендерүче журналисты идегез.

Зөлфия ГЫЙМАДИЕВА

Аерылышкач, никах та өзеләме?

Ирем аерылышырга гариза бирде. Берничә көннән суд утырышы булачак. Әгәр ирем судта: «Мин хатынымнан аерылырга телим», – дип әйтсә, бу инде талак әйтү белән бер булып саналамы? Ул шул сүзләрне әйткәч, суд рәсми рәвештә аергач, безнең никах та автомат рәвештә өзелгән булып саналачакмы? Әллә никахны аерым өзәсе булачакмы?

Исемем редакция өчен генә

Булат МӨБАРӘКОВ, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать мәсьәләләре бүлеге башлыгы, Казан казые:
– Юк, ир кешенең судта, хатынымнан аерылырга телим, дип әйтүе талак әйтү булып саналмый. Бу – теләк белдерү генә. Ә менә суд сезне рәсми рәвештә аерган һәм ирегез үзенең ризалыгын белдергән вакытта бу бер тапкыр талак әйтү булып санала. Талак әйтүнең шартлары нинди? Әгәр ир кеше үзенең хатынына: «Талак», – дип әйтә икән, ул бер талак булып санала. Аннан соң яңадан кушылырга була әле. Ике тапкыр әйтсә дә, мондый мөмкинлек саклана. Әгәр инде ир кеше өч талак әйтә икән, бу очракта инде алар кире кушыла алмыйлар. Ник дигәндә, Аллаһы Тәгаләнең әмере бар һәм ул «талак»ларның санын чикли. Ир кеше талак әйткәндә шаһитлар булу шарт түгел.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

28 август | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «СВАТЬИ». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Кев Салихов 16+
00.25 «Каравай» 6+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Алсу Тимергалина турында телеочерк 16+
13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
15.30, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.35 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
01.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
02.35 «Таяну ноктасы» 16+
03.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Алсу Тимергалина турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Повара на колесах» 16+

1 РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко, Роман Маякин, Александр Голубев, Мария Порошина, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов, Дмитрий Ульянов, Анастасия Стоцкая, Никита Тезин. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ! МАТЧ ТВ

06.00 «Звёзды без правил» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 09.35, 12.55, 14.40, 17.00 Новости
07.05, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.40 Бильярд. Снукер. Кубок мира. Финал. Прямая трансляция из Тюмени
12.35, 01.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.45 Смешанные единоборства. UFC. Макс Холлоуэй против Чэн Сон Джунга. Трансляция из Сингапура 16+
16.00, 00.35 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
17.05 «Громко» Прямой эфир.
18.25, 01.55 «География спорта. Санкт-Петербург» 12+
18.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Арсенал» (Тула) – «Торпедо» (Москва). Прямая трансляция.
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Кальяри» – «Интер». Прямая трансляция.
02.25 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 6+
02.55 Новости 0+
03.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Луис Паломино против Джеймса Лилли. Трансляция из США 16+
04.00 Гребля на байдарках и каноэ. Чемпионат мира. Трансляция из Германии 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 19.00, 23.15 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Остросюжетный сериал «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
23.40 Премьера. «Путь бойца» 18+
01.00 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

Д ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.40 «Порча». «Кнопка вызова» 16+
13.10 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «ПУАНТЫ ДЛЯ ПЛЮШКИ» 16+
19.00 «СОКРОВИЩЕ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.25 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «МАМА». 5-я – 8-я серии 16+
05.40 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня. 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 00.45 «ЕРМАК». Телесериал. «РОЖДЕНИЕ АТАМАНА» 16+
12.10, 13.25, 03.20 «БАЛАБОЛ». Телесериал. «ПОСЛЕДНИЙ ПАССАЖИР» 16+
15.00 Военные новости. 16+ .
15.10, 17.15 «БАЛАБОЛ». Телесериал. «ЗДРАВСТВУЙ, ПАПА!» 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Зенитная артиллерия». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж». 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ПОСТАРАЙСЯ ОСТАТЬСЯ ЖИВЫМ» 12+
01.40 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+

29 август | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «СВАТЬИ». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Казань музыкальная. 80-е годы 6+
00.50 «Соотечественники». Рафаэль Юнусов. Народный директор 16+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30, 20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Бөркет канатында хөрлек бар». Язучы Адлер Тимергалин турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Хоккей не футбол» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Фаина Раневская» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+

1 РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Карина Андоленко, Роман Маякин, Александр Голубев, Мария Порошина, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов, Дмитрий Ульянов, Анастасия Стоцкая, Никита Тезин. «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ! МАТЧ ТВ

06.00 «Звёзды без правил» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.40 Новости
07.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Горьян Славески против Джейка Линдси. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.45 Футбол. FONBET Кубок России. «Рубин» (Казань) – «Урал» (Екатеринбург). Прямая трансляция
17.00 Футбол. FONBET Кубок России. «Факел» (Воронеж) – «Оренбург». Прямая трансляция
19.15 Футбол. FONBET Кубок России. «Спартак» (Москва) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф. Прямая трансляция
01.25 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф 6+
03.25 Новости 0+
03.30 «Здоровый образ. Хоккей» 12+
04.00 Регби. PARI Чемпионат России. «Локомотив-Пенза» – «Металлург» (Новокузнецк) 12+

НТВ

04.40 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Остросюжетный сериал «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
23.40 Премьера. «Путь бойца» 18+
01.00 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

Д ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.35 «Тест на отцовство» 16+
11.45 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Чёртово перо» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.55 «Верну любимого» 16+
14.30 «Голоса ушедших душ» 16+
15.05 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА МИЛЛИОНЕРА» 16+
19.00 «ОТ ВСТРЕЧИ ДО РАЗЛУКИ» 16+ Россия, 2022 г.
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.25 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «БАЛАБОЛ». Телесериал. «ЗДРАВСТВУЙ, ПАПА!» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.10 «ЕРМАК». Телесериал. «ЦАРСКИЕ ОСЛУШНИКИ» 16+
12.10, 13.25, 03.20 «БАЛАБОЛ». Телесериал. «АМЕРИКАНСКАЯ КОЛЛЕКЦИЯ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.10, 17.15 «БАЛАБОЛ». Телесериал. «ПОЛКАН» 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Бронекатера». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Погружение» Байдена. Зачем так долго искали «Титан»?» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «ГОЛУБЫЕ ДОРОГИ» 12+
02.00 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте инфраструктура һәм чимал проектлары буенча баш консультанты, «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы президенты (Казан шәһәре) **Кантюков** Рәфкать Габделхәй улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы **Җиһаншин** Илшат Рәхимҗан улы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы **Мөхәммәтҗанов** Радик Усман улы, «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең Үзәк районы администрациясе оештыру эше бүлеге башлыгы, район администрациясе аппараты җитәкчесе **Хафизова** Резеда Фаикъ кызы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хемницер** Алевтина Дмитриевна, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәил авыл җирлеге башлыгы **Йосыпов** Рифнур Гайнан улы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Чистай шәһәреннән ун баланың ата-анасы **Ермолаев** Юрий Аркадьевич, **Ермолаева** Наталия Ильинична **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Азнакай муниципаль районы буенча Азнакай шәһәреннән биш бала анасы **Хәсәнова** Гүзәл Садретдин кызы, Саба муниципаль районы буенча Килдебәк авылыннан биш бала анасы **Хәлимова** Гөлия Фәнис кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Россия почтасы» акционер җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Нурлат районара почтамты 423042 Нурлат почта элемтәсе бүлекчәсе почтальоны **Гафурова** Зәйтүнә Хәмәтвәли кызы, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе корреспонденты **Гыйлемханов** Риман Солтан улы, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе Әлмәт территориаль органының эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге башлыгы **Җәләтова** Лилия Миңнегани кызы, «Татинтек» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең метрология идарәсе башлыгы **Садыйков** Рим Зиннур улы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының яшеренлек режимын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы секторы мөдире **Хәсәнов** Айрат Рашат улы, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Шакиров** Илфат Фоат улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

АРУ ГЫНА ТҮГЕЛ

Россиядә яшәүчеләрнең өчтән бере хроник арыганлыктан интегә. Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) белгечләре ил халкы арасында сораштыру уздырганнан соң шундый нәтиҗәгә килгән. Белгечләр чаң суга: элегрәк бу халәт, нигездә, 40–60 яшь аралыгындагы кешеләргә генә хас булса, хәзер ул яшьләр арасында да еш күзәтелә башлаган. Ул нәрсәсе белән куркыныч? Хроник арыганлыктан ничек котылырга?

Казанның 7 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Карина ХӘЙРЕТДИНОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Хроник арыганлык гадәти арудан нәрсәсе белән аерыла?

– Хроник арыганлык вакытында кеше күпме генә ял итсә дә, күпме генә йокласа да, арыганлыгы бетми. Бу халәтнең иң төп билгесе шул. Хроник арыганлыктан интеккән кеше көн дәвамында хәлсез йөри. Хроник авыруның ни сәбәпле килеп чыгуы әле дә булса билгесез булып кала бирә. Шулай да ул организмга макронутриентлар (аксым, май, углевод һ.б.) һәм микронутриентлар (минераль матдәләр, витаминнар) җитмәү, аллергия, кешенең озак вакыт дәвамында физик һәм психик киеренкелек халәтендә яшәве аркасында килеп чыгарга мөмкин дип фаразлана.

:: Хроник арыганлыкны организмдагы нинди үзгәрешләр буенча чамаларга мөмкин?

– Әйткәнемчә, кеше көн дәвамында хәлсезлектән интегә. Ул таркау, игътибарсыза әверелә. Баш әйләнү, йокысызлык яки, киресенчә, аягүрә йоклап йөрү кебек билгеләр күзәтелергә дә мөмкин. Бу халәт өч-дүрт айдан да артыграк дәвам итсә, борчылырга җирлек бар.

:: Мондый арыганлык нинди чир билгесе дә була ала?

– Әйе, хроник арыганлык җитди чир барлыгы турында да кисәтергә мөмкин. Аерым алганда, ул организмда инфекцияле, паразитар чирләр, калкансыман биз, аутоиммун авырулар, яман шеш вакытында да күзәтелә ала. Психик авыруы булган кеше дә еш кына хроник арыганлыктан интегә.

:: Ул дәвалауга бирешәме?

– Кызганыч, конкрет шушы халәттән генә дәвалану алымнары юк. Әгәр хроник арыганлык чир билгесе булса, ул чакта нәкъ менә шул чирдән дәваланырга кирәк. Калган очракларда, хроник арыганлыктан котылу өчен, гомуми киңәшләргә колак салырга: ял һәм эш режимын көйләргә, дөрес тукланырга, В, С витаминнары, минераль матдәләр эчәргә киңәш ителә. Физик күнегүләр, дәвалау массажы ясау да артык булмас.

:: Хроник арыганлыкны ничек булдырмый калырга?

– Беренче билгеләре күренүгә үк, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Иң беренче чиратта терапевт, невролог, клиник психологка күренү хәерле. Хроник арыганлыкны кисәтү өчен, күбрәк саф һавада йөрергә, дөрес тукланырга, стресслардан сакланырга, күңелгә якын булган яраткан шөгыльләренә, хоббига вакыт табарга кирәк. Көн саен ярты сәгать йөгерү дә артык булмас. Елга бер тапкыр булса да профилактик тикшерену узарга тырышыгыз.

:: Җаен ялны тулысынча алу файдалыракмы? Әллә икегә бүлеп алу хәерлерәкме?

– Һәр кешенең организмы индивидуаль. Бу очракта да бер кешегә озын ял килешсә, икенчесенә ул, киресенчә, зыянга гына булырга мөмкин. Әмма медицина ягыннан караганда, ялны бүлеп алу организм өчен күпкә файдалырак. Ник дигәндә, бер ай ял иткән кешенең организмы тулысынча ял итүгә генә күнегеп бетә. Шул рәвешле аңа эшкә керешеп китү өчен дә күбрәк вакыт кирәк булачак. Бу – организм өчен зур стресс.

vk.com

НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

Хроник арыганлыкны сизгәндә туклануга аеруча игътибар итәргә кирәк. Рационда аксым, май, углеводлар – барысы да булырга тиеш.

✓ Көнгә биш-алты тапкыр аз-азлап ашагыз.

✓ Көн дәвамында В витаминына (балык, бавыр, кош ите, йомырка, кузаклылар, шпинат, банан, чикләвек), С витаминына (цитруслар, киви, гөлҗимеш, кәбестә, яшел борчак, яшел алма) бай ризыклар, составында Омега-3 һәм Омега-6 булган продуктлар (әстерхан чикләвеге, чиа орлыгы) ашарга кирәк.

✓ Көн дәвамында 2–2,5 литр чиста су эчәргә дә онытмагыз.

✓ Камыр ризыкларыннан, тозлы, майлы азык-төлектән, кәһвә, исерткеч эчемлекләрдән баш тарту хәерле. Алар хәлегезне тагын да авырайтачак кына.

Киңәш-табыш

Саулыкны урлаучы 6 дошман

1 Ит деликатеслары (бекон, дуңгыз ите, сосискалар). Алар канцерогеннар буларак классификацияләнә һәм еш кулланылган очракта йөрәккан тамырлары авыруларын көчәйтә, яман шеш китереп чыгара. Әйтик, көн саен 50 г эшкәртелгән ит, мәсәлән, колбаса ашасаң, эчәкләрдә яман шеш барлыкка килү куркынычы 18 процентка арта, ди белгечләр.

2 Ак оннан әзерләнгән ашамлыклар (ак икмәк, токмач, дөге). Боларны еш һәм күп ашасаң, шикәр чире һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары барлыкка килү ихтималы бермә-бер арта.

3 Ясалма тәмләткечләр белән татлы газлы су. Татлы эчемлекләр һәм ашамлыкларның сәламәтлеккә тискәре йогынты ясавы күптән расланган инде.

4 Грильдә пешкән ит. Югары температурада әзерләгәндә, гетероциклик аминнар һәм полициклик углеводородлар кебек канцероген кушылмалар бүленеп чыга. Алар үз чиратында юан эчәк һәм ашказаны асты бизе яман шеше, шулай ук йөрәк-кан тамырлары авыруларын китереп чыгарырга мөмкин. Хәтта микродулкынлы мичтә пешерү дә, мангалда әзерләнгәнгә караганда, зыянсызрак, ди белгечләр.

5 Трансмайлы ризыклар: кыздырылган, фритюрда әзерләнгән ризыклар (гамбургер, фри бәрәңге, тавык канатлары һ.б.). Аларны еш ашау ялкынсынуга, йөрәк авыруларына, инсультка, диабетка, бавыр авыруларына илтә һәм башка хроник чирләр барлыкка китерә.

6 Кофеин күп булган энергетик эчемлекләр йөрәкне көчәнеп эшләргә мәҗбүр итә һәм ул аритмиягә китерә. Аларда шикәр чамадан тыш күп була.

Үзем сынадым

КӨЗӘН ҖЫЕРМЫЙ

Аякны көзән җыерудан суганның файдасын күрәм. Моның өчен аның кабыгын төнәтергә кирәк. Бер чәй кашыгы вакланган суган кабыгына бер стакан кайнар су салып, 10 минут төнәтәсең. Аны йоклар алдыннан эчсәң, төнлә аякны көзән җыермый.

Әтнәдән Әлфия апагыз

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

БЕР ТӨПТӘН – 50 БӘРӘҢГЕ?!

Социаль челтәрдә: «Дуслар, ышанасызмы? Бер төптән 50 бәрәңге чыкты», – дип язылган видео таралганнан соң, әлеге «могҗиза» турында сорашырга булдык. Әгерҗе районының Кичке Таң авылында гомер итүче укытучы Эльмира Зиннәтуллинаның мондый хәлне күргәне булмаган.



– Узган елларда теге бәрәңгене казып алдык. Орлыгын үзебездәге бер шәхси кибеттән алган идек. Моңа кадәр «Мадейра», «Беллароза» сортларын сатып алып үстергән идек. Быел «Вега» сортын сынап карарга булдык. Бәрәңгенең кайберсе я сабын кебек, яки бөтенләй таралып бетә торган ялучан була. Ә бу сорт шуларның урталыгында дияр идем.

Эче сары түгел, андыйны яратмыйм. 5 кг утыртып, барлыгы 190 кг (10 литрлы 22 чиләк!) уңыш җыеп алдык. Һәр төптән 50 түгел, 20–25 чамасы бәрәңге чыкты. Әлбәттә, бездә уңгач, башкаларда да шулай мул уңыш бирер, дип әйтеп булмый. Чөнки аны 15 еллап бәрәңге утыртылмаган, моңа кадәр азык чөгендере, ташкабак үскән, рәхәтләнеп ял иткән урынга утырткан идек. Юкка гына җирне ял иттерергә кирәк димиләр бит. Җәй уртасында бер генә тапкыр су сиптек. Яңа сортлар сынап, урыннарын алыштырып утыртырга яратам. Социаль челтәрдә күргәннән соң, сатып алырга теләүчеләр, почта аша җибәрергә сораучылар да бик күп булды. Алай кыйммәт була, сатып түгел, болай да бирәм, дидем. Ә авылдашлар белән икенче сортларга алыштырырга сөйләштек.

«Бәрәңге уңуның тагын бер сере – иртә утыртуда», – ди Эльмира ханым. Ел саен апрель ахыры, май башыннан да калмый утырта икән алар «икенче икмәк»не.

– Аңа үсеп житү өчен шул вакыттагы дым җитә. Бик тирән түгел, 10 см чамасы гына итеп күмәбез. Дым кирәк булса, бәрәңге, үзе эзләп, аска таба китә ул, – ди Эльмира ханым.

Тәмле булсын!

МИЧТӘГЕ ТАШКАБАКЛАР

Кирәк: *зур булмаган 2 данә ташкабак, 3 аш кашыгы үсемлек мае, 2 тырнак сарымсак, тоз, ысланган паприка, 2 данә помидор, 100–150 г сыр.*

Ташкабакларны боҗралап турап, пергамент җәелгән табага тезәргә. Сарымсак, тоз, май, паприканы болгатып, ташкабакларга сөртеп, 20–25 минутка 180 градуска кадәр кыздырылган мичкә тыгабыз. Мичтән алып, өстенә боҗралап киселгән помидорларны тезәбез, өстенә уылган сыр сибәбез һәм 5–7 минутка кабат мичкә куябыз. Бик тәмле һәм файдалы кабымлык әзер!

Хуҗабикәгә

САРГАЙСА

Пластик контейнерларның эчләре саргайса, аны урталай киселгән лимон белән ышкып алыгыз. Аннары контейнерны кояш төшкән урынга куеп, кипкәнен көтегез яки микродулкынлы мичкә берничә секундка тыгып алыгыз. Бераздан чиста су белән юыгыз. Тапның эзе дә калмаячак, тәмле ис тә килеп торачак.

Белеп тор!

Үкчәгә бал кирәк

Үкчә ярылып интектергәндә, бал белән зәйтүн маеннан компресс ярдәмгә килә. Үкчәдәге ярылган урыннарга тигез итеп бал белән зәйтүн маен болгатып сөртегез һәм йомшак чүпрәк белән төреп куегыз. Бал белән әлеге май тирене тукландыра һәм дымландыра.

Исеңдә тот!

Тузаннан коткара

Бүлмә гөлләренең яфрагына тузан тиз генә утырмасын өчен, түбәндәге ысулларны кулланырга була.

- 1:1 күләмдә су һәм сөт кушып ясалган катнашма белән сөрткәннән соң, яфрак өстендә юка гына элпә сыман катлам барлыкка килә. Ул яфракларны ялтыратып җибәрү белән берьрәттән аны пәрәвез талпаны иялешүдән дә саклый.
- 1 литр суга 1 төймә гәрәбә кислотасы (янтарная кислота) салынган катнашма гөлләрнең иммунитетын күтәрә, яшь яфракларын арттыра.
- Ярты литр суга 2 аш кашыгы спирт һәм 1 аш кашыгы глицерин салып ясалган катнашма яфракларны тузаннан арындыруда тыш, зыян күргән яфракларны яңартып, терелтеп тә җибәрә.
- 1 стакан суга 1/4 чәй кашыгы лимон кислотасы салып ясалган катнашманы сиптергәндә гөлләрнең яфраклары ялтырап торачак.

Розаны терелтәбез

1. Ваннага яки ләгәнгә розалар тулысынча күмелерлек итеп салкын су тутырабыз.
2. 10 см чамасы сабагын кисәбез.
3. Чәчәкләрне 5–12 сәгатькә тулысынча суга салып тотабыз.

Газетада басылган киңәшләрне социаль челтәрләргә урнаштырганнан соң, андагы укучыларыбыз безгә яңа киңәшләр бирәләр. Аларның кайберләрен сезгә тәкъдим итәбез.

Кәбестәне кисмәгез

Кәбестәне саклау өчен, тамырын кисмәскә кирәк, бераз җилләтергә, аннан соң тамырыннан базга элеп куярга. Газетага төрүнең кирәге юк, болай да язга кадәр бик яхшы саклана.

Гомәр ГЫЙЛЕМХАНОВ

Гөмбә тозлар чак

Гөмбәләрне бик яхшылап юып, тозлы суда 15–20 минут пешерәм. Күбеген җыеп барам. Банка һәм капкачларны содалы су белән стерилизацияләштерәм. Тозлыкны 3 л суга 3 аш кашыгы тоз салып ясыйм. Банка төбенә 1–3 тырнак сарымсак, 3–4 данә кара борыч, бераз горчица орлыгы салам. Банкага пешкән гөмбәләрне тутырып, өстенә тозлык коям, 1 бал кашыгы серкә салам һәм каплап куям.

Гүзәл КӘРИМОВА

Чөгендерне катырам

Мин чөгендерне күп итеп пешереп, угычта уып, суыткычның туңдыра торган өлешендә саклыйм. Борщ пешерәсе булганда, кисеп, тәлинкәгә салам, өстенә 2 аш кашыгы алма серкәсе сибәм, аш шулпасы өстим. Ашны сүндергәч, аңа чөгендер салам. Төсе матур, тәме бик тәмле була.

Гүзәл ГАРИПОВА

Кош теле сере

2 йомырка һәм тагын ике йомырканың сарысын гына алып, әз генә (пычак очында) тоз, 1 чәй кашыгы сода, 1 аш кашыгы исле үсемлек мае салып, йомшак кына итеп камыр басам. Аннары бераз туң май өстәлгән үсемлек маенда пешерәм. Бик тәмле була!

Рәйсә АЙЗЯППАРОВА

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ҮЛЧӘП АЧ

Әйткән сүз – аткан ук, ди халык. Телдән бер ычкынса, сүзне кире җыеп алырмын, димә. Сүз белән кешене юатып та, киресенчә, рәнҗетеп тә була. Нахак сүз булса, бигрәк тә. Бер гөнаһсызга әйтелгән сүзләр еш кына үз артыннан «рәнҗеш», «каргыш» дигән төшенчәләрне дә ияртә. Нахакка рәнҗетсәләр, ни эшләргә? Бер гөнаһсызга кимсетелгән кешенең каргышы кабул буламы?

Бу сораулар белән Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВка мөрәҗәгать иттек.

:: Нахак сүзгә динебез нинди мөнәсәбәттә? Бу хакта хәдисләрдә нилләр әйтелә?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әгәр сез кешедә булган нәрсә турында сөйләсәгез, бу гайбәт була. Әгәр сез кешедә булмаган нәрсә турында әйтсәгез, ул бөһтан (нахак) булачак», – дигән. Гайбәт тә, нахак та динебездә зур гөнаһлардан санала.

:: Дөрес сүзгә ышанмыйча, ялган, нахакка ышану – ахырзаман галәмәте, диләр. Бу, дөрестән дә, шулаймы?

– Әйе, дөрестән дә, шулай. Бу хакта пәйгамбәребезнең бер хәдисендә дә телгә алына. Анда: «Ахырзаман билгесе – ялган сөйләгән кешеләрне – дөресен сөйләүчегә, дөрес сөйләүчене ялганчыга санарлар», – дигән юллар бар. Шул рәвешле ялган, нахакка ышану ахырзаман билгеләренең берсе булып тора.

:: Әгәр кеше нахакка гаепләнгән кешене якласа, моның өчен савабы булачакмы?

– Нахакка гаепләнүчене яклауның әҗер-савабы бик зур. Динебездә оялу хисе яхшы хис санала. Әмма бу очракта ике искәрмә бар. Беренчедән, белем алган вакытта оялырга ярамый. Ул чакта әлеге сыйфат начар санала. Гаделсезлек, залимлек, нахакка гаепләү белән күзгә-күз очрашкан очракта кеше, оялып, эндәшмичә торырга тиеш түгел. Киресенчә, хаклыкны сөйләп, гаделлек урнаштырырга тырышырга тиеш. Моның өчен, әйткәнемчә, аңа әҗер-сабавы да булачак.

:: Нахакка рәнҗетелгән кеше каргаса, аның бәддогасы кабул булачакмы?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Бер гөнаһсызга рәнҗетелгән кешенең күз яшеннән курык. Аның белән Аллаһы Тәгалә арасында бернинди киртә дә юк», – дигән юллар бар. Шул рәвешле нахакка рәнҗетелгән кешенең догасы да, каргышы да кабул булырга мөмкин. Бу – бик куркыныч нәрсә. Шуңа күрә гаделсезлеккә бик сак карарга, кеше рәнҗетүдән сакланырга кирәк.

:: Әгәр сине нахакка рәнҗетсәләр, нахак сүз әйтсәләр, ни эшләргә?

– Әгәр мөмкинчелек булса, сезне рәнҗеткән кеше белән очрашып, барын да уртага салып сөйләшергә кирәк. Юк икән, дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән сорарга кирәк. Коръәни Кәримдәге «Әл-хиҗр» сүрәсендә: «Алар синең хакта сөйләгән әйберләр турында без беләбез. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләгә хәмәтсана кыл һәм сәҗдә кылучылардан бул», – ди.

Сентябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ясту намазы
1	Җом	02:20	04:47	16:24	18:38	20:33
2	Шим	02:24	04:49	16:22	18:36	20:30
3	Якш	02:27	04:50	16:20	18:33	20:27
4	Дүш	02:30	04:52	16:18	18:31	20:23
5	Сиш	02:33	04:54	16:16	18:28	20:20
6	Чәрш	02:36	04:56	16:14	18:25	20:17
7	Пәнҗ	02:39	04:58	16:12	18:23	20:13
8	Җом	02:42	05:00	16:10	18:20	20:10
9	Шим	02:45	05:02	16:08	18:18	20:07
10	Якш	02:48	05:04	16:06	18:15	20:04
11	Дүш	02:51	05:06	16:03	18:12	20:00
12	Сиш	02:53	05:08	16:01	18:10	19:57
13	Чәрш	02:56	05:10	15:59	18:07	19:54
14	Пәнҗ	02:59	05:12	15:57	18:04	19:51
15	Җом	03:01	05:14	15:55	18:02	19:48
16	Шим	03:04	05:16	15:53	17:59	19:45
17	Якш	03:07	05:18	15:51	17:57	19:42
18	Дүш	03:09	05:19	15:48	17:54	19:39
19	Сиш	03:12	05:21	15:46	17:51	19:36
20	Чәрш	03:14	05:23	15:44	17:49	19:33
21	Пәнҗ	03:17	05:25	15:42	17:46	19:30
22	Җом	03:19	05:27	15:39	17:43	19:27
23	Шим	03:22	05:29	15:37	17:41	19:24
24	Якш	03:24	05:31	15:35	17:38	19:21
25	Дүш	03:26	05:33	15:33	17:35	19:18
26	Сиш	03:29	05:35	15:31	17:33	19:15
27	Чәрш	03:31	05:37	15:28	17:30	19:12
28	Пәнҗ	03:33	05:39	15:26	17:28	19:10
29	Җом	03:36	05:41	15:24	17:25	19:07
30	Шим	03:38	05:43	15:21	17:22	19:04

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йәгез, бер дога!

ГАФУ ИТҮНЕ ҮТЕНГӘН ДОГА

«Әллаһүммә мәгъфиратүкә әүсәгү мин әунүүбии үә рахмәтүкә әрҗәә гиндии мин гамәли».

Мәгънәсе: «Әй, Аллаһы! Синең мәрхәмәтең минем гөнаһларыма караганда зуррак һәм минем гамәлем белән чагыштырганда Синең шәфкатең шулкадәр зур ки, шәфкатең миңа өмет өсти».

Локман Хәким нәсыйхәтләре

Локман Хәкимнән: «Авыруга нәрсә ашатыйк?» – дип сорагач, «Ачы сүздән башка бөтен нәрсәне ашата аласыз», – дип җавап биргән.

Кешене һәлак итә торган сыйфат – ачкүзлек. Ул безне, барына канәгать булмыйча, ышанычсыз әйбер артыннан чабарга мәҗбүр итә, нәтиҗәдә булганны да югалтабыз.

Тыңларга теләгең булмаса да, үз кардәшеңне бүлдерми тыңлап бетер, аның хөрмәтен урынына җиткер. Артык сөйләшү – идарә итү тезгенен шайтанга тапшыру. Тел белән кылынган җәрәхәт кылыч белән яралаудан авыррак.

Хатының белән күркәм мөгамәлә кыл, аны иркәлә. Назны читтән эзләргә мәҗбүр булмасын.

Аллаһ тышкы кыяфәтегезгә һәм байлыгыгызга карамый. Ул күңелләрегезгә һәм йөрәкләрегезгә карый.



Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Мин = милләт

Асыл

Александра телләр өйрәнә, лингвист белгечлегенә укый. Биергә ярата, төрле конкурсларда катнаша. Сашага сәяхәт итү ошый. «Сәяхәтләр – үзеңне иреклe итеп тою, башка мәдәниятләр белән танышу өчен мөмкинлек», – ди ул.

АЛЕКСАНДРА ДАШИДОРЖИЕВА, БУРЯТ, 19 ЯШЬ

ТАТАРСТАНДА КЕШЕЛӘР ҮЗ МӘДӘНИЯТЕН КАДЕРЛИ БЕЛӘ, миңа әнә шул ошый. Аларда башка милләтләргә карата кызыксыну да бар. Миңа мондый мохиттә үземне, асылымны, милли үзенчәлегемне күрсәтү бик рәхәт. **КАЗАНДАГЫ ДУСЛАРЫМНЫ БУЗА БЕЛӘН СЫЙЛАРГА ЯРАТАМ.** Көндәлектә милли кием киям һәм милли бизәнгечләр тагып йөрим.

Быел Казанның төрле сәхнәләрендә бурят биюе белән чыгыш ясарга насыйп булды. Мондагы халык бик яратып каршы алды, алкышлады. **АЛАРНЫҢ ИХЛАС КЫЗЫКСЫНУЫН, СОКЛАНУЫН КҮРҮ СӨЕНДЕРӘ ҺӘМ ИЛҺАМЛАНДЫРА**.

ГАИЛӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ КАДЕРЛИ ҺӘМ ХӨРМӘТ ИТӘ. Әйтик, без Яңа елны Юлиан календаре буенча түгел, ә Ай календаре буенча билгеләп үтүгә күбрәк өстенлек бирәбез. **ЯҢА ЕЛ АЛДЫННАН «ПАКЬЛӘНӘБЕЗ». БУ – ТИРӘ-ЮНЬНЕ ЧИСТАРТУ ГЫНА ТҮГЕЛ, ҮЗЕҢНЕ ЧИСТАРТУ ДА.** Яңа елга бер атна кала зур учак ягып, кием кисәген шунда ташлыйбыз. Аңа кадәр кием кисәген тәннән йөртеп чыгабыз. Шул рәвешле без тәнебездәге һәм рухыбыздагы негативтан котылабыз.

Яңа елда гаиләбез белән иртүк торабыз, Балдан Лхамо дигән алиһәне каршы алабыз. Риваятькә ышансаң, ул нәкъ иртән күктән җиргә төшә, өйләрендә ут янган кешеләрнең өе аша очып үтә. Бик күп итеп буза пешерәбез. Барлык кунакларга җитсен өчен! Яңа елның беренче атнасында туган-тумачалар белән кунакка йөрешү каралган. «Ак ризык»лар белән генә тукланырга тиеш без ул көннәрдә. Ягъни сөт ризыклары инде бу. **ГАДӘТТӘ, БУРЯТЛАРНЫҢ БӘЙРӘМ КӨННӘРЕНДӘ ТАБЫНДА СӨТЛЕ ЯШЕЛ ЧӘЙ, САЛАМАТ, БУЗА, ИПИ, ЭРЕМЧЕК БУЛА**.

Игъланнар сайтын ачып карасаң, Көек авылы чыннан да төпсез кое кебек тоела. Биредә әлеге бистәдә йорт сатылуга бәйле утызлап игълан очраттык, әле тагын да бардыр, алга таба санамадык. Бәяләре төрле: бер катлы кирпеч «тартма»лар 5,5 миллион сумга да, 12 миллион сумга да бар.

– Яңалык шәхси торак төзелешенә кагылмый, шуңа күрә без элек ничек эшләсәк, алга таба да шулай дәвам иттерәчәкбез, – ди Көектә коттеджлар сату белән шөгыльләнүче «Купи дом» төзелеш компаниясе вәкиле Диана. – Борчылырга сәбәп юк. Тәкъдим җитәрлек. Әзер йортлар сатабыз. Аларның барлык документлары да бар.

Татарстан риэлторлар гильдиясе вице-президенты Андрей Савельев сүзләренә караганда, хакимият карарын моннан берничә ел элек үк кабул итәргә кирәк иде.

– Аңлашыла ки, Казан эчендә төзелеш өчен әллә ни зур мәйданнар калмады. Шуңа күрә шәһәр тирә-юньдәге территорияләр хисабына киңәя. Әмма бу эшне алдан уйлап башкарырга кирәк, – ди белгеч. – Шул ук Лаеш районында, мәсәлән, бик күп төзелешләр алып барыла. Тиешле чаралар күрелмәсә, бер-ике елдан биредә социаль һәм юл-транспорт афәте килеп чыгачагы көн кебек ачык. Шуңа күрә Казан янәшәсендә төзелеш эшләренә рөхсәт бирүне чикләүне бик дөрес дип саныйм. Моны элегрәк эшләргә кирәк иде. Ә төзүчеләргә килгәндә, моңа кадәр рөхсәт алучылар үз эшләрен ничек бар, шулай дәвам иттерәчәк. Ә киләчәктә план төзүгә җаваплырак карарга, күпкатлы йорт төзү өчен урын сайлаганда уйлабрак эш итәргә туры киләчәк. Яшел Үзәндә дә төзелеш мәйданнары шактый. Әмма биредә мәсьәләне алдан хәл итәргә тырышу сизелә. Мәсәлән, бүген биредә урап узу юлы төзелә, Казанга керү-чыгу юлында Горький шоссесын киңәйтәләр.

Сан

Ел башыннан бирле Татарстанда 2 миллион 523 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. Бу – еллык планның 81 проценты. Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин сүзләренә караганда, төзелеш эшләренә 500дән артык рөхсәт бирелгән. Димәк, республикада тагын 3,9 миллион квадрат метр торак төзеләчәк. Соңгы өч айда Татарстанда милек базарында сату-алулар 130 процентка арткан.

Риэлтор Наилә Гарифуллина әйтүенчә, тәңкәнең ике ягы булган кебек, һәр үзгәрешнең уңай һәм тискәре яклары бар.

– Шәһәр читендә яңа йортлар салуга рөхсәт бирүне чиклиләр икән, димәк, төзелеп килүче күпкатлы йортлардагы фатир бәяләре кыйммәтләнәчәк, – ди белгеч. – Бу исә башкалада торак бәясе тагын да артуга китерәчәк. Бер яктан, Казан тирәсендә яшәүчеләрнең тормыш шартларын яхшыртырга теләсәләр, икенче яктан, түбәле булырга хыялланучыларның өметен өзәләр. Үзәк банк төп ставканы 12 процентка кадәр күтәргәч, сорау азмы-күпме кимер дип фаразлаган идек. Юк, безгә мөрәҗәгать итүчеләр саны күбрәк тә әле. Июль аенда гына да Казанда 1,5 меңнән артык фатир сатылган. Бу – быелның беренче яртысында сатылган барлык торакның өчтән бере. Ел азагына кадәр башкалада яңа йортлардагы фатирның бер квадрат метры 200 мең сумлык чикне дә узарга мөмкин. Хәзер әлеге сан 190 мең сумны тәшкил итә. Чагыштыру өчен: ел башында гына ул 170 мең сум иде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

АВЫЛ БИРГӘН КӨЧ

Казандагы 18 нче гимназиянең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Рәмзия Шәрәповага «Татарстанның халык укытучысы» исеме бирелде. Шәһәрдә туып, шунда белем бирсә дә, беренче адымнарын авылда башлаган ул. Менә шул тәҗрибәне бүгенге дәрәҗәгә ирешүдә төп нигез дип саный.

...Йомшак кулларын, яратып, иңемә куюыннан, ипле сөйләменнән үк ниндидер җылылык тойдым. Юк, мин аның укучысы түгел, әмма аныкы кебек хис иттем үземне. Һәр укучы өчен иң мөһиме әнә шул җылылык шул.

:: Рәмзия Мидхәтовна, шәһәр кызын, ягъни яшь укытучыны авыл мәктәбе укучылары ничек кабул итте?

– Мин Казанда туып-үстем. Башкаладагы 77 нче мәктәпне, аннан Казан педагогия көллиятен тәмамладым. Укып бетергәч, иптәш кызыма ияреп, Апас районының Болын-Балыкчы сигезьеллык мәктәбенә укытырга кайттым. Ул вакытта укып бетергәч, өч елга юллама белән җибәрү гадәте бар иде. Комиссия җитәкчесенә бардым да: «Мин авылга кайтам», – дидем. Һәм моның өчен бер дә үкенмәдем. Искиткеч мәктәп иде ул. Директоры – сугыш ветераны, орденнар иясе, бик шәп укытучы Габделхак Сәмигуллин. Без аны абый дип йөртә идек. Нәкъ менә ул мине укучыларны яратырга, ныклы белем бирергә өйрәтте. Аның киңәшләрен гомер буе истә тоттым. Дәрескә һәрвакыт сөенеп кердем. Авыл баласы күзгә карап, сине йотлыгып тыңлый. Шуны күреп, бар белгәнемне өйрәтергә тырыштым. Анда 3,5 ел эшләдем. Читтән торып институтка укырга кергәч, шәһәр мәктәбендә эш тәкъдим иттеләр. 45 ел узгач, укучыларым Болын-Балыкчы авылына кунакка чакырды. Алар да минем кебек өлкән инде. Нибары 7–8 яшькә генә яшьрәк. Балаларым миңа ничек дәрес бирүем турында сөйләде. Бергәләп су коеныргa баруыбыз, велосипедта йөрүләрне искә төшерделәр. Ульян шәһәрендәге музейга, Казандагы театрларга алып баруымны да онытмаганнар. Шунда алган тәҗрибә мине бүгенге уңышларга, дәрәҗәгә китерде. 49 ел стажым бар. Моңа кадәр Татарстанның атказанган укытучысы идем, менә хәзер – халык укытучысы.

:: Мәктәптән китәсегез килмиме?

– 50 нче елымны башлыйсым килмәгән иде, әмма укучыларым, укытучылар китмәвемне сорый. Мәктәп директоры да: «Рәмзия Мидхәтовна, осталыгыгызны яшьләргә җиткерергә кирәк», – дип үгетләде. Яшь хезмәттәшләремнең күбесе – минем укучыларым. Вуз тәмамлап, практикага килделәр дә гимназиядә укытырга калдылар. Алар белән горурланам. Укытучы һөнәр түгел, ул – күңел кушкан эш. Менә шуны аңлаганнар мәктәптә укыта ала да инде.

:: 18 нче татар гимназиясенә ничек килеп эләктегез? Татар рухы барыбер күңелегезне күбрәк җылыта кебек...

– Әлеге гимназия 42 нче мәктәп базасында татар мәктәбе булып ачылды. Шул вакытта мине фәнни тәҗрибә мәйданчыгы директоры урынбасары итеп билгеләделәр. Ул вакытта уку йортының номеры да юк иде әле. Аннан статус бирделәр. Гимназия ачылганнан бирле биредә 30 ел хезмәт куям. Данлыклы гимназия! Элеккеге директоры шагыйрь Равил Садыйков та бик ипле, культуралы булды. Укучылары, укытучыларына багышлап шигырьләр яза иде хәтта. Төпле коллектив оештырды. Татар мәктәбе нинди ул, дисезме? Андагы балалар телне саклый. Татарча чаралар уздырыла, тәнәфесләрдә туган телдә сөйләшәбез. Һәр дүшәмбе барлык укучылар гимн җырлый. Биш оныгым бар. Берсе татар-төрек мәктәбендә белем алса, калганнары шушы гимназиядә укый. Туган телне белүләрен, Татарстанның горурлыгы булып үсүләрен телим.

:: Яңа уку елында нәрсә көтәсез?

– Каникул вакыты бит, ял итәбез. Шулай да җәй көне үз фәнемә кагылышлы үзгәрешләр белән кызыксындым. Укучыларны БДИга әзерлисем бар бит. Шөкер, сынауларда югары баллар җыялар. Алар белән горурланам. Яңа уку елында олимпиадада җиңүчеләремнең күбрәк булуын телим.

2023 ЕЛДА ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ЯХШЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНА ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕКТӘГЕ КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН ПРЕМИЯЛӘР БИРҮ БӘЙГЕСЕНДӘ

91 укытучы катнашкан, 33е җиңгән

БӘЙГЕДӘ КАТНАШУЧЫ УКЫТУЧЫЛАРНЫҢ ФӘН БУЕНЧА НӘТИҖӘЛӘРЕ

Фән	Ничә укытучы катнашкан?	Җиңүчеләр саны
Рус теле һәм әдәбияты	14	6
Химия	7	6
Чит телләр	13	5
География	4	3
Математика	6	3
Башлангыч сыйныф укытучылары	12	3
Тарих, җәмгыять белеме	5	2

Фән	Ничә укытучы катнашкан?	Җиңүчеләр саны
Татар теле һәм әдәбияты	14	2
Технология	3	1
Физика	4	1
Физик культура	3	1
Биология	3	-
Башка фәннәр	2	-
Сәнгать белеме	1	-

Сораштыру

Чәчәк җәл түгел

Белем көнендә укытучыларга чәчәк бүләк итү – күркәм гадәт. Әмма «Альфа Страхование» компаниясе уздырган сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, илдә әти-әниләрнең 64 проценты моны «кирәкмәгән чыгым» дип саный. Уртача алганда, бер букет бәясе 3 мең сумга төшә икән. Гаиләдә берничә бала булганда кесәгә шактый суга, билгеле. Тик укытучыны шушы игътибардан да мәхрүм итеп булмый бит инде. Сез ничек уйлыйсыз?

Нурисә ИБӘТУЛЛИНА, Арча районы Ашытбаш мәктәбенең биология укытучысы:

– Чәчәксез 1 сентябрь сәеррәк булыр инде ул. Аны бит сатып алырга димәгән. Авылда балалар үзләре дә үстерә. Элеккеге фотоларда да укучылар кулларына чәчкә, сумка тотып укырга барган. Гади чәчкә алып килсәләр дә, үпкәләмибез. Элек без укытучыларга урманнан җыеп бүләк итә идек. Әти-әниләргә чыгым инде. Мәктәпкә дә әзерлисе бар бит. Укытучыга 2–3 мең сумлык букет кирәк түгел.

Ландыш НӘСЫЙХОВА, ике бала анасы:

– Белем көнендә бәйрәм рухы булырга тиеш инде. Укытучыга хөрмәт билгесе бит ул. Мин бер дә каршы түгел. Тик бер укытучыбызга чәчәк аллергия бирә. Шуңа күрә аңа җиләк-җимешләрдән ясалган букет бүләк итәчәкбез. Икенчесенә исә 27 розадан торган гөлләмә бирергә сөйләштек. Һәр укучы бер чәчәк алып киләчәк.

Гөлүсә САДЫЙКОВА, Казандагы 149 нчы лицейның башлангыч сыйныф укытучысы:

– Биш мең сумлык букет алыйк, диючеләр бар. Акчагызны әрәм итмәгез, дим. Бер-ике көн торгач, без аны ташлыйбыз. Бер сыйныф исеменнән бер букет бирсәләр дә риза. Кайбер әти-әниләр башта үзләре ризалаша да аннан, балам ничек мәктәпкә чәчәксез бара инде, дия башлый. Юк, улымның яки кызымның кулына чәчәк тоттырачакмын, ди. Аннан күреп, икенчесе тагын да яхшыракны сайлый. Мин чәчәккә киткән чыгымнарны кызганам.

Зилә ГЫЙЛЬМАНОВА, студент:

– 1 сентябрьгә чәчәк алып бармас идем. Ул бит кибә. Шул акчага берәр кучтәнәч алыр идем. Бәлки, укытучыга берәр кирәк-ярак. Әйтик, ак кәгазь яки канцелярия товары. Чәчәкне туган көненә бүләк итәргә мөмкин. Сыйныфтагы һәр бала берәр чәчәк алып килсә ярый. Бер гөлләмә бирү иң яхшысы дип саныйм.

Тимур ФӘЙЗУЛЛИН, 6 нчы сыйныф укучысы:

– Чәчәк бит ул – укытучыга хөрмәт билгесе. Безне гаиләдә шулай өйрәттеләр. Белем көненә букет тотып барырга читенсенмим. Бер елны әни кашкарыйлар гына алып кайткан иде. «Әни, ник розалар алмадың?» – дидем. Матур букет бирү – үзе бер рәхәт бит ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Гөлгенә
ШИҺАПОВА

УРЛАНГАН... МӘХӘББӘТ

Казахстанда кыз урлаган өчен җәзаны катгыйландырмакчылар. Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил моның өчен җинаять җаваплылыгы кертергә тәкъдим итә. Әле моннан 10 еллап элек Татарстанда да кыз урлау гадәте бар иде. Бездә бөтенләй риза булмаган кешене урламыйлар. Шулай итеп гаилә коручылар арасында Мамадыш районының Түбән Яке авылында да матур гомер итүче гаиләләр бар. Бу язмамны башкалар да кыз урлап өйләнсен дип түгел, заманында йоласына туры китереп өйләнешкән парларның матур итеп яшәүләренә сокланып әзерләдем.

РАФАИЛ + ГӨЛФИДӘ

Гөлфидә апа белән Рафаил абый Гариповлар инде 40 елга якын бергә матур тормыш итәләр. Икесе дә Түбән Яке авылыныкы алар. Бер сыйныфта укыганнар. Мәктәп елларында берберсенә күз дә ташламаганнар, сүз дә катмаганнар.

– Мин авылда хат ташучы булып эшләдем. Әти белән әни кунакка киткәч, без өйдә дус кызым Фәйрүзә белән икәү генә калдык. Ул көнне авылдашыбыз Рифатның солдат ашы иде. Сеңлем шунда. Бермәлне ишек шакыйлар. Сеңлемнең йөргән егете килеп керде. Янында Рафаил абыең да тора. «Безгә син кирәк. Сине алырга килдек», – диләр. Рафаил, мин сиңа өйләнәм, ди. Бер дә очрашып карамаган кешеләр идек бит без, – дип искә ала яшьлек елларын Гөлфидә апа.

Баксаң, егетләр бәхәсләшкән булган. Рафаил абый авыл егетләренә, мин бүген өйләнәм, дип ычкындырган икән. Ә сүзне үтәргә кирәк. Әти-әнисенең кайтуын да көтмәгәннәр, көзге пычракта Гөлфидә апаны урлап алып киткәннәр.

– Өйләренә килеп кердем дә еладым. Читен булды инде. Әле бит әти белән әнине дә уйлыйм. Шунда булачак каенанам: «Риза булып төштеңме?» – дип сорады. Нәрсә дим инде. Кире кайтырга уйламадым да. Аның бит сүзе була. Бер сыйныфта укыгач, бөтенләй ят кеше түгел иде Рафаил. Нәселен беләм. Почтада эшләгәч, пенсияләр дә кертәм. Каенанам, бу кыз кемне бәхетле итәр икән дип, гел артымнан карап кала торган булган. Үз малаена насыйп булдым.

Баштарак иләшү кыен була. Әмма тормышлары тиз җайлана аларның. Уртак тел дә табалар. Бер-бер артлы өч балалары туа.

– Без яшь чакта бер дә сүзгә килмәдек. Талашып гомерне әрәм итеп ятмадык, аңлашып яшәдек. Рафаил абыең бер дигән ир булды. Гаиләндә хөрмәт, бер-береңне аңлау булса, яратуның башы шул инде, – ди Гөлфидә апа. – Бер дә үкенмәдем. Тормышым шөкер итәрлек булды. Хәзер инде оныклар сөябез, балалар бәхетенә сөенәбез. Төп йортта улым һәм киленем белән яшибез. Өч оныгыбыз бар. Гомернең матур көзенә кердек.

Кыз урлау – борынгы йола. Ул әти-әнинең хәер-фатихасы булмаган очракта башкарыла. Урланган кыз егет өендә кунса, ул инде мәсхәрәләнгән булып санала һәм гадәттә аңа бүтән ир-егетләр карамый. Нәтиҗәдә кыз, тешен кысып булса да, үзен урлаучыга кияүгә чыгарга мәҗбүр. Шунысын да әйтергә кирәк: татарларда бары таныш кызларны гына урлаганнар. Әгәр дә кызны эләктереп качканда арттан куа чыксалар, кызны гадәттә калдырып киткәннәр. Ул очракта аның намусына хилафлык килми.

ИЛНАР + ИЛГИЗӘ

Фазылрахмановларның тормыш итә башлауларына 15 елдан артып киткән. Илнар Илгизәне бер күрүдә ошата. Очрашулары 1 сентябрьдә була. Күрше авыл кызы Түбән Якегә балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә килә. 18 сентябрьдә инде Илгизәне урлап алып кайталар.

– Илнар белән сөйләшкәләп йөрдек. Әмма болай тиз өйләнешербез дип уйламаган да идем. Аның 18 сентябрьдә туган көне булды. Ул анда мине дә чакырды. Әнә шунда нишләптер күңелемә, урласалар, нишләрмен, дигән уй килде. Уем чынга ашты. Әти белән әни каршы килмәгәч, мин калдым. Иртәгесен никах укыттык. Кешеләр очрашканда бер-берсен белеп бетерсә, без яшияши төрле яктан ачылдык, – ди Илгизә.

Илнарлар – ишле гаилә. Барысы җыелганда 35 кешегә җитәләр икән. Атна ахырында 15 кешедән дә ким кунак кайтмый. Илгизә шундый зур гаиләгә килеп керә. Үзе әйтмешли, биредә бәхетен таба.

– Иремнең апаларына рәхмәтлемен. Алар мине беренче көннән яратты, үз итте. Исемем белән дә эндәшмәделәр. «Яным» дип кенә торалар. Каенанам да тыныч, акыллы кеше минем. Килен булып килгәч, үз әниемне югалттым. Бик авыр чак иде. Әнә шул вакытта Илнарның һәм туганнарының җылы карашын тойдым. Алар минем хәсрәтемне җиңеләйтте, – ди ул.

Фазылрахмановлар өч бала үстерә. Илнарны мактап кына тора Илгизә. Ә үзен бөтен авыл кешесе ярата. Сүз көрәштерми, гайбәт сөйләп йөрми, тавышланып, талашып тормый. Кешене тыңлый, үзенекен эшли.

– Ирем бер теләгемә дә каршы килмәде. Авыр сүз әйтми, туганнарымны хөрмәт итеп яши. Мин дә аныкыларны яратам. Илнарның бар туганы да, нәрсә эшлик, нинди эшләр бар, дип кенә торалар. Бердәм алар, бар эшне күмәк башкаралар. Тату яшибез. Алар кайтмаса, безгә бик читен. Бер дә авырсынмыйм, кайтуларын көтәм. Бик күңелле яшибез, – ди Илгизә. – Матур яшәүнең сере гади аның. Кайчагында эндәшмәскә, күпне күрмәскә кирәк. Ачуланышудан ни файда соң? Тормышка сөенеп, булганга шөкер итеп яшәүдән дә рәхәте юк. Мин язмышыма бик рәхмәтлемен. Олы улыма 14 яшь тулды, уртанчы кызыбызга – 10, кечесенә – 3 яшь. Аларны алты айлык чагыннан әниебез карады. Шунысы өчен аерым рәхмәт аңа. Бар кешегә дә минекедәй каенана телим. Аның белән тагын озак еллар бергә яшәргә насыйп булсын. Әни безгә бик кирәк. Аның йөрәгендә һәркем өчен урын табыла.

ӘСГАТЬ + РАЙЛӘ

Бер күрүдә яраттым! Әсгать абый Райлә апаны урлап алып кайтып өйләнүен әнә шулай дип аңлата. Шуңа да башкаларга бирәсе килми. Тәвәккәлли дә урлый. Ике авыл арасы якын түгел. Түбән Яке егетләре, кичке уенга килгән кыяфәт ясап, Райлә апаны саклап торып, машинага утырталар.

– Без Әсгать белән күрше авылда таныштык. Ул чакта аның йөргән кызы да бар иде. Баксаң, ул мине күргән дә гашыйк булган. Миңа өйләнер дип уйламадым да. Ә менә авылга Яке егетләре килгән дигәч, йөрәгем жу итте. Сизендем. Клубтан шыпырт кына чыктым да тиз-тиз өйгә кайтып киттем. Артымнан ниндидер машина кузгалды. Бик тиз куып җиттеләр. Ике егет чыкты да мине машинага утыртты. Кычкырмасын дип, безнең өйгә таба киттеләр. Инде өйгә җитәм дигәндә, машина борылды да, Әсгатьләргә кайтып киттек. Әти белән әни мине югалткан. Кайтмагач, кешедән сорашып, артымнан килгәннәр иде. Алар мине кире алып китте, – дип искә ала Райлә апа Абдуллина.

Әмма Әсгать абыйның ухҗәтлеге көчле була. Өйләнәм дигәч өйләнә. Райлә апаны барыбер алып кайта. Инде менә 27 ел бергә яшиләр.

– Гомер бик тиз үтте. Инде балалар буй җиттеләр. Бер дә үкенмәдем, язмышыма үпкәләмәдем. Әсгать мине кадерләп яшәтте. Үзем дә бик яраттым аны. Күзләргә карап та аңлашабыз хәзер. Яши башлагач, яратасың да, хөрмәт тә итәсең. Ир кешенең сиңа булган мөнәсәбәте гашыйк та иттерә, бәхетле дә итә. Тулы бәхетебезгә күз тимәсен, – ди ул.

Белеп тор!

Кыз урлаган өчен Җинаять кодексының 126 нчы маддәсе буенча җаваплылык каралган. Уйнап кына урлау булмаса, ул бик четерекле эшкә әйләнә, аның өчен җавап тотарга кирәк булачак. Моның өчен 5 ел мәҗбүри эшләтү яки шул ук вакытка кадәр иреккә мәхрүм итү каралган. Әгәр дә көч кулланып, янап, акча алу өчен, шулай ук балигъ булмаган яки көмәнле кешене урласалар, бу очракта 5–12 елга кадәр төрмәгә утырту каралган. Урлаган кеше, сәламәтлегенә зыян салмыйча, тотыкны җибәрә икән, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

КОМПОЗИТОР РИЗВАН ХӘКИМ – АВТОРЛАР ТУРЫНДА:

«УРМАННАН ЧЫГА АЛМЫЙ ИНТЕГӘЛӘР»

Җыр бизнесы вакытлыча гына. Халык, шоу-шулардан арып, барыбер элекке эзенә кайтачак. Композитор, Татарстанның атказанган артисты, Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ризван ХӘКИМ шундый фикердә. Җыр кайчан языла? Композитор, халыкка карап, нәрсәне билгели? Эстрадага ни җитми? Без әнә шул хакта сөйләштек.

«Татар-информ»

:: Җыр язуны кәсепкә санаучылар бар, сезнең өчен нәрсә ул?

– Ходай биргән талант дип уйлыйм мин аны. Я була ул, я юк. Бар инде, үзләре сүзләрен язып, көен дә чыгарып, үзләре җырлаучылар, үзләре үк үзләренә кул чабучылар да. Гәрчә һуш китәрлек бернәрсәләре булмаса да, рәвешен китерергә тырышалар. Җырны язгач, халык җырларлык итеп язарга кирәк. Халык җырыңны җырламаса, син юксың. Халык җырыңны җырласа, син композитор буларак кирәксең әле. Мин шулай уйлыйм.

:: Музыка – математика, диләр...

– Ниндидер формулалар уйлап чыгарып, шуның буенча эшләүчеләр дә бардыр. Хәзер ясалма акыл дигәне дә барлыкка килде. Әмма минем өчен музыка ниндидер кысаларга, кагыйдәләргә буйсына торган нәрсә түгел. Музыка ул – күңел эше. Сүзләр күңелгә тисә, музыка үзеннән-үзе туа. Мин сүзләргә бик талымлы. Заманында Башкорт дәүләт университетының татар бүлеген тәмамладым. Бәлки шуңа да сүзләргә бик бәйләнчектер инде мин. Тапталган сүз яки фикергә тап булсам, күңел кайта. Шуңа күрә шагыйрьләрем дә санаулы гына. Әйтик, соңгы елларда Марат Кәбиров, Нәфисә Сабирҗанова белән бик күп җырлар иҗат иттек. Шигырьләр күп бирәләр анысы, укып кына карыйм да... Урманга кереп китә бит әле кеше, шулай болар да кереп китә һәм чыга алмыйча интегәләр. Җыр өчен бөтен кеше дә текст яза алмый шул.

:: Радио тыңлыйсызмы?

– Бик тыңламыйм. Телевизорны да яңалыклар һәм спорт карар өчен генә кабызам.

:: Музыка яңалыклары белән кайдан танышып барасыз?

– Музыкаль каналларда кем түләгән – шул җырлый. Анда яңалык та, зәвык та юк. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Әйбәт җырны әйбәт дисең инде аны. Элегрәк Фирзәр Мортазин, Илгиз Закиров иҗат итә иде ичмасам, их, дип куя идең сокланудан.

> **Мин гел: «Илгиз Закировның «Әнкәмнең догалары»ннан соң әниләр темасына кагылырга кирәкми», – дим. Дөресе шул аның. Әниләр темасына язарга кирәк, әйе. Әмма аннан да үтемлерәк итеп тагын кем иҗат итә алыр соң? Ай-һай, белмим...**

Хәзер их дип әйтерлекләре күренми, мөгаен, шуңа элеккеге җырларны яңадан сорап алалар да бугай инде. Эстраданы шул тиклем дә бозарга ярамый иде инде. Шоу-программа дигән булып нәрсәләр генә эшләмиләр бит. Безнең халык надан түгел ул. Авыр чакта җырлап, кайгысын баскан, шатлыгын да җырлап уртаклашкан. Шул моңнар кире кайтыр, димен. Талантлы яшьләр бар бит әле. Халык җырын җырлаучылар да бар. Халык җыры – тавыш мөмкинлекләренә барометр ул. Җырлый ала икән, сәхнәдә үзенә урын таба, юк икән – юк инде. Акча ничә буынны бозды, әмма мин өметләнәм әле. Җырлау акча белән бәяләнә торган нәрсә түгел.

> **Халык, димәктән. Безнең якларда хәзер мәҗлесләргә артистлар чакырмый башладылар. Үзем, баян алып, берничә шундый мәҗлестә булып кайттым, шулкадәр күңел булды. Рәхәтләнеп җырлашып, тәнәфестә ду китереп биеп ял иттеләр. Менә ичмасам күңел ачу. Ихлас чакларны сагыну инде бу.**

:: Татар эстрадасында сезнең җырларны башкармаган җырчы юк дисәк, дөрес булырмы?

– Юк бугай шул. Әйтмичә, сорамыйча да җырлыйлар. Сорап алсалар, күңел була инде.

:: Беренче җырыгыз нинди иде?

– «Елама, ярсыма». Шушы җырдан башланды барысы да. Беренче мәхәббәтемә багышлап яздым да, Туймазы шәһәрендә яшәп иҗат итүче композитор, шагыйрь Әкрам абый Даутов бар иде, аңа күрсәттем. Зур кеше иде ул, тикмәгә генә күп җырлары халыкныкы булып китмәгәндер. Кыскасы, Әкрам абыйдан кыяркыймас кына, сүзләре дә, көе дә үземнеке инде, ярарлыкмы, дип сорадым. Озын-озак сүзләр сөйләп тормады, «Улым, киләчәгең зур», – диде. Шулай дәрт өстәп җибәргәч, яза башладым.

:: Хәтер, димәктән. «Нәфисә» төркеме хәзер дә бармы?

– Хәзер дә бар. Бу исемне мин хатыным Нәфисә Хәкимованың фаҗигале вафатыннан соң, истәлек булсын дип куштым. Аңа кадәр ул «Могҗиза» исемен йөртте һәм сәләтләр ачу үзәге буларак эшләде. Хәзер дә Нәфисә белән бергә башлаган эшне дәвам иттерәбез. Менә әле Линар Белый дигән талантлы бер егет белән эшлим. Бу төркемнән бик күпләр үсеп чыкты. Заманында Радик Юльякшин да биредә иде бит. Шушы ансамбльдә дүрт ел чыгыш ясады. Линар да – бик талантлы егет. Әтисе татар, әнисе башкорт, ике телдә дә җырлый. Заманында без Нәфисә апаң белән дуэт башкаруны кертеп җибәргән идек бит. Хәзер барысы да, дуэт җырлыйбыз, дигән булалар инде. Я ирен җитәкләп килеп чыгалар, я хатынын. Дуэт бит ул бергә җырлау гына түгел, ул тулы бер спектакль булырга тиеш. Ә андыйны күптән күргәнем юк инде.

Безнең төркемгә килергә чират торалар. Монда гел яшьләр. 12 кешелек состав белән дә эшләгән булды, 7 кешегә калган чаклар да. Әле менә яңа программа әзерләп ятабыз. Казан халкына исә ноябрьдә «Ризван Хәкимовның алтын хитлары» программасын күрсәтергә исәп. Кемнәр минем җырларны башкара – шулар чыгыш ясар дип уйлыйм. Уфада без аны куеп карадык инде. Зал ике көн шыгрым тулы булды.

:: Соңгы вакытта җырчылар җырга хокукны тулаем сатып алалар да башкаларга җырларга рөхсәт бирмиләр.

– Мин тыю яклы түгел. Җыр җырланырга тиеш. Мин аны тарткалаш объекты була алыр дип күз алдына да китерә алмыйм. Заманында кемдер җырлап, сүрелеп калса, бүген аңа яңа сулыш өрәләр икән, аның зыяны юктыр дип уйлыйм.

:: Нәрсәнедер үзгәртергә мөмкинлек бирелсә, нәрсәне үзгәртер идегез?

– Үткәннәр ачы сабагын да, барысын да бирде. Мин рәхмәтле язмышыма. Әле кулдан нидер килә, эшлим, яшим әле.

:: Тормышта таянычыгыз бармы?

– Балаларым, яраткан кешем бар. Шулар белән бәхетлемен.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Ризван Хәким турында 7 кызыклы факт

✓ Спортны ярата. Бокс һәм чаңгы буенча беренче разрядлы спортчы.

✓ Мәктәпкә укырга кергәндә укый-яза белә. Башкалар хәреф өйрәнгәндә, ул газета укый торган була. 5 нче сыйныфка кадәр уку кызык түгел иде, дип искә ала.

✓ Беренче җырны 19 яшендә яза.

✓ Хәрәкәт кешесе. Бер урында тик торырга яратмый.

✓ Ирек ярата. Кушылган темага, вакыт белән чикләнгән конкурсларны да, темаларны да яратмый. Заманында филармониягә эшкә чакырсалар да, хатыны Нәфисә Хәкимова белән төркем оештырып, үзләренә эшли башлыйлар.

✓ Шоу сүзен яратмый. Җырчыларга: «Шоу – пәри туе дигән сүз. Телең – татар теле, динең – ислам икән, сәхнәдә пәри туе оештырма инде син», – дип киңәш бирә.

✓ Композиторлар фестивале оештыра. Авторлык хокукларын яклар, авторлар белән халыкны таныштырыр өчен башлый бу эшне.

ЛИЛИЯ ФӘТТАХОВА

«СЕЗДӘ НИНДИ ХӘЛЛӘР БАР?..»

Фирая-Фая читтә яшәүчеләрнең күпчелеге өчен үтә дә якын, ә чын татарның үтен сытарлык «фирменный» теле белән миңа соңгы күрсәтмәләрен бирә:

– Ну ты же меня понял инде, Тофик. – Тофик ул – мин, аңардан биш яшькә олырак булган абыйсы Тәүфыйк. – Как только бетерәсең эшләреңне, сразу же езжай туда. Адресны мин сиңа вот здесь записал. И фотографии наши детские заберешь, и әбинең китапларын. Незачем им там ятарга. Сам понимаешь.

Фираяның әни карчык белән генә сөйләшә торган тагын бер теле бар. Монысы инде меланхолик хатынның минутына егерме сүз әйткәне рәвешендәрәк яңгырый:

– Син бит беләсең… бит инде… әни… килә алмыйм мин… көн дә… мин… бит эшлим бит… күп бит эш…

Һәр сүзен башта урысча уйлап, аннары татарчага тәрҗемә итә-итә җык була Фирая. Аның шулай азапланууларын карап тору көлке дә, кызганыч та. Бер дә азапланмас иде, әни карчык урысча эндәшкәнгә кайтарып җавап бирми. Мировой әни ул безнең! Әле шулай нык булып та, дүрт баласының икесе генә аның белән үз телендә сөйләшкәнне күреп тору үзәген өзәдер. Һай, өзәдер. Оныкларны әйтеп торасы да юк. Фираяның бер кызы атасы ягындагы әбисе йогынтысына бирелеп, тәре тагып, исем алыштырып кайткач, ни диясең… Язмыш җилләре туган авылыннан меңнәрчә чакрым ераклыкка илтеп ташлаганда, нәселенең шулай пыран-заран килерен белгән булса, ире-насыйбына иярмәс кенә иде дә бит. Барыбер рәхәт күрсәтмәде. Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмыйдыр шул.

Әти дигән кешебез белән әнкәбезнең аралары ул Пермь урманнары эчендәге лагерьга «утырма»га киткәнче үк бозылган иде. Артыгы белән «табигать баласы» иде әти: ирлек дәрте никахлы хатыныннан башкаларга да җитә иде. Әнкәй башта дүрт бала хакына түзде бугай, аннары чираттагы төнге маҗарасыннан соң, «кайдан кайттың – шунда кит» дигәнме, атабыз чыгып киткән. Ул кадәресе миңа караңгы. Үземнең бала чагым үткән якка якынрак булыр дип, Казанда укып йөри идем ул вакытта. Мин кунакка кайтканда, алар инде аеры-чойры яшәп яталар иде. Әткәйнең гадәтләре хакында белмәслек яшьтә түгел идем – сорау биреп тормадым.

Фираяның бүгенге ярты сәгатьлек күрсәтмә-нәсыйхәте атабыз дүрт ел гомерен үткәргән лагерьга бәйле иде. Дөресрәге, шунда чагында яшәгән йортта калган бер төргәкне кайтартмакчы ул. Нинди уйлар белән җибәрттергән булгандыр, әбием нинди дер чыбык очы туганнар аркылы улына берничә догалык белән безнең фотосурәтләрне җибәргән булган икән. Шул турыда ишетеп алган сеңелкәш, ә ул безнең ут борчасы кебек, адресларын да юнәткән, әти мәрхүмне белгән кешеләргә дә чыккан, аңардан калган әйберләрнең бер чемоданга салынып чормада сакланганын да белеп алган. Минем шул якларга командировкага җыенуымны ишетеп алуга, эченә корт кергән менә.

Соңгы арада мәчеткә йөри башлады әле Фираябыз, намазга да басты. Дин буенча белеме диңгез өстендәге күбекне генә хәтерләтсә дә (кемнән нәрсә ишетә – шуны дөрес саный), әбиебездән калган дини китапларның теләсә кайда урыс-улак арасында аунап ятуын теләми, имеш. Кеше күңеле – карурман шул. Кайчандыр җиде яшькә яшьрәк Коля атлы урыс егетен үзенә өйләндергән кеше ул. Мескен Коляның (үз ихтыяры булмаган һәммә мәхлук мескен инде минем өчен) тәресен салдыртып, яши башлауларының икенче елында «мөселман» ясаган кеше. Үз динен дә юньләп тотмаган кияү балакаебыз ислам диненнән дә бихәбәр инде ул. Фирая өчен анысы мөһим түгел. Тәресе юкмы – юк. Тәрене яратмау әллә геннардан күчә инде ул: әни карчык та, тәренең сурәтен генә күрсә дә, догаларын укырга керешә. Иң ачуланганда әйтелә торган сүзе дә: «Чукынчык!»

Әти карап торышка катлаулы кеше түгел иде кебек. Ә тормыш юлына карасаң, бормалы да катмарлы. Әле анда сулга каерган арбасы, әле монда мәтәлгән. Гадәттә, аның чордашлары – туган авылларыннан йөз чакрымнан да ераграк китмәгән, дүрт йә булмаса җиде класс (монысы сирәгрәк) белеме булган агайлар. Калага китеп төпләнүчеләре сирәк, авылда калганнары, тәмен табып, бәрәңгесен үстерә, малын карый, көтү көтә. Җигелеп, колхоз йөген тарта: иген игә, азык әзерли… Гадәткә кергәнчә, җаен туры китереп, колхоз малын (димәк, үзенекен) чәлдерә, аз-маз «шайтан суы»н авыз иткәли. Әти бераз гына аерылып торды ул. Була бит әле шулай: тип-тигез генә үскән арыш-бодай арасында тырпаеп сузаебрак торганнары да очрый. Буй да, чынлап та, Аллага шөкер генә. Безнең авылда аның кебек озын буйлы гөрнәдирләр санаулы гына иде. Тавыш бөердән чыга, чәчләр шомырт кара. Кирелеге, башбирмәслеге дә вакыт-вакыт чамасыз була иде аның. Шул кирелеге аркасында колхоз рәисләре белән дә тыныша алмады. Шул кирелеге аркасында авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булдык. Пермь урманнары арасына килеп эләгүенә дә шул холкы сәбәпче булгандыр дип уйлыйм. Язмыш, дияргә ярата әнкәй. Язмышын язмыш та, ялгышлары кемнеке соң аның? Бераз гына сабыррак, бераз гына тотнаклырак, бераз гына акыллырак булса әтиебез, без дә хәзер Рәсәйнең очсыз-кырыйсыз җирләренә таралмаган булыр идек кебек… Әнкәй дә, радиодан берәр татар җыры ишетүгә, көннәр буе үз эченә бикләнеп:

Атамның бер гөле идем,
Анамның былбылы идем,
Бу хәсрәткә гаҗиз булдым,
Сабыр бирсен үзе Аллаһ, –

дип, мөнәҗәтләрен көйләп йөрмәс иде.

Әнкәй карчыкның шундый чагын күргән саен, йөрәккәй кысылып куя. Әтинең вафатына дистәгә якын вакыт үтсә дә, күңел төпкелемә кереп урнашкан үпкә-рәнҗү бетмәгән иде әле. Фираяның үтенеченә дә (таләбенә дисәң дөресрәктер) теләр-теләмәс кенә ризалаштым. Әтигә бәйле хатирәләрне яңартасым килми минем. Әллә ташлап китү сәбәпле утырды ул юшкын, белмим.

Әти эзләреннән йөрү теләге белән түгел, ак яулыклы газиз әбиемнең үз куллары белән күчереп язган догалык китабын, безнең болай да сирәк булган бала чак фотоларын кайтару нияте белән генә ризалаштым мин Фираяның үтенеченә. Мин әти баласы булудан бигрәк, бабакаем белән әбекәем баласы идем шул.

Әле дә хәтеремдә: ап-ак итеп акшарланган мич каршына кабасын алып килеп утыра да йон эрли әбекәй. Үзе ишек катынарак утырып, агачтан кашыклар юнып утырган бабакай белән гәпләшә.

– Атасы, карале, бөтен кешедә дә җен бар, дигән китап. Элегрәк безнең карт мулланы җен чыгарырга чакыра иделәр, дип сөйлиләр. Хәзер андый нәрсәләр ишетелгәне юк инде, име?

– Җен бар инде ул, шул котырта бит инде адәм баласын…

Алар тыныч гына сөйләшеп утыра, ә мин мич башындагы җылы урынымда изрәп йокыга китәм дә төшемдә әллә нинди койрыклы нәрсәкәйләр белән саташа башлыйм. Ул койрыклы нәрсәгә галстугым белән селтәнә-селтәнә: «Җен-фәлән дип сөйләнүләр искеләрдән калган ул!» – дип тә җиффәрәм әле. Үзем куркам, үзем батыраям, имеш. Их… Ярый әле, әбекәй без авылдан кузгалганчы догалар өйрәтеп өлгергән. Гел искә төшмәсә, бер искә төшә. Саклап йөрткән кебек алар. Аннары урыс арасына күчкәч, ни әнкәйдән, ни әтидән алла, дин дигән сүзләр чыкмады. Заманасы да «кызыл» заман иде шул, тирәлеге дә чит-ят.

* * *

Эшләрем тәмамланганда, көн кичкә авышып бара иде инде. Көзнең әбиләр чуагыннан соң башланып киткән пыскак яңгырлы соры көннәре шагыйранә кызгылт-сары өрәңгеләрнең дә җетелеген киметкән, болай да күңелсез уйлар тулган башым тирә-юньнән бер ямь тапмый. Өскә ишелеп төшкән болытлы күк сытып китәр төсле, күз кабаклары авыраеп йомылырга тора. Кунакханә бүлмәсендә җылыдыр, яктыдыр. Ләкин… ләкин… Мин машинамны кирәкле юнәлешкә борам да ике сәгатьләп юлны радиодан агылган таныш көйләр, таныш дикторлар хозурында дәвам итәм. Юл буендагы күрсәткеч миңа кирәкле «Лагерь» пунктына җиткәндә, радиотанышларның туйдыра башлаган тавышларыннан качып, машина тартмасыннан дисклар эзләргә тотынган идем, кулым үзеннән-үзе рульгә ябышты. Бу тирәлектә уяу булу кирәк. Кичәге зэклар поселогы булса да, шикләндерә. «Кичәге»ләр булмый ул: йоклап кына ята торгандыр кебек «җен»нең иң кәттәләре.

Ахыры бар >

Шигърият

Рифат СӘЛАХ

ҖӘЙ БӘЙРӘМЕ

Җиләк исе керә тәрәзәдән,
Гөлчәчәкле җитез җил исә.
Кояш бүген ап-ак күлмәк кигән,
Ак болытлар шундый килешә.

Чирәмнәргә кунган көмеш чыкта
Бөтен галәм нуры чагыла.
Җәй җылысы бүген гомерлеккә
Күчеп калыр төсле җаныма.

Офыкларда елгыр балкыш уйный,
Зәңгәр күккә сеңгән йолдызлар.
Һәр игелек өчен алкыш ява,
Кыйбласына кайта юлсызлар.

Кыйбла җиле тулы җиләк кенә,
Гөлчәчәккә тулган бар дөнья.
Гомер елгасыннан төшеп бүген
Йөрим әле яшәү багында.

БҮГЕН ГЕНӘ

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Моңа кадәр гүя булмадым.
Алсу таңның йомшак чыгы сыман
Тәгәрәде шигырь юлларым.

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Кичә генә җансыз идем мин.
Бүген генә йолдызлары янды
Кап-караңгы тонык күгемнең.

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Кичә генә җирдә төн иде.
Бүген иртән йомшак таң чыклары
Күз нурларым булып түгелде.

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Моңа кадәр әллә булмадым.
Сезнең өчен җырлар яза-яза
Тәгәрәде гомер йомгагым.

Мин дөньяга бүген генә тудым
Һәм атылдым җиргә ук сыман.
Моңа кадәр гүя яшәлмәгән
Шигъри мизгелләрне юксынам.

ҖИЛЛӘР СЫМАН ОЧЫП КИЛӘСЕҢ

Җилләр кебек очып киләсең,
Коңгырт чәчләреңне таратып.
Бер гомер дә бигрәк аз булыр,
Туя алмам сине яратып.

Җилләр булып очып киләсең –
Иләсләнер күңел бер дәвер.
Эх, каласы иде яшьлектә
Синең белән генә бергә-бер.

Эх, каласы иде яшьлектә,
Башка беркем белмәс сер илә.
Җилләр сыман очып киләсең
Сәгадәткә, җырга, сөюгә.

Җилләр мәңге тынмас син булган
Мәхәббәтле якты дөньяда.
Чәчләреңдә синең гүяки
Коңгырт төсле якты төн яна.

Очып-очып миңа киләсең,
Җилең генә китә кагылып.
Бер гомер дә бигрәк аз булыр,
Туя алмам сине сагынып.

СИРӘК КУЛЛАНЫЛУЧЫ СҮЗЛӘР

Игътикат	ышаныч
Мәхбүс	тоткын
Шаталак	тиктормас
Тиктәс	әһәмиятсез
Шаһбаз	батыр
Игътизар	үтенеч
Сөрхәнтәй	ялкау
Истиһза	мәсхәрә
Дәхел	мөнәсәбәт
Тәнбиһ	кисәтү
Мөмтаз	бүтән
Андау	кузәтү
Бурлат	куе кызыл
Кыҗрау	омтылу
Шәрафәт	хөрмәтле
Алчак	оятсыз
Ләфхәтән	бөтенләй
Кязип	ялганчы
Ләкатә	табылдык
Сыза	коры елга
Биртәк	тотлыгучы
Касәм	ант

Әз-мәз мәзәк

Бөтен җирдә ялган. Ә кайбер җирдә әле алдау да.

* * *

– О! Руслан! Танымадым сине! Тиздән баерсың!

– Мин Руслан түгел.

– Ой, гафу итегез, бу арада гына байый алмассыз.

* * *

Фитнес-клуб – иң рәхәт ял чарасы. Хатыным залга киткәч, шундый шәп итеп ял итәм.

* * *

Мин япон галимнәренең бик күп трактатларын укыдым. Әмма берни аңламадым. Чөнки японча белмим.

* * *

Күргәзмәдә бер хатын:

– Нинди матур пейзаж. Бу рәссамның телефонын бирә алмассызмы?

– Картинасын сатып алырга телисезме?

– Юк, рәссамның кайда ял иткәнен беләсем килә.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: яки, алпавыт, ас, Ирек, ми, тоз, чык, шок, Рәшит, Вәлиев, ион, Сара, лангбот, шәл, олпат, Сабыр, би, ре, бәрән, ОК, мут, ар, Австрия, Никулин, гив, Ан, Лилиана, Смак, ил, урт, рота, Ливан, Переяслав, чал, Рафаил, атна, ни, им, Резидә.

Вертикаль: автор, Наил, Ленин, Алып, Ив, Абдулла, шелтә, Ли, Заһитова, Раилә, рок, әрни, партер, ипсез, иген, елан, Боб, Айнур, Фаяз, Ява, Носов, Арена, кысмыр, такси, ТӘ, Инид, ит, икәү, Сәлимә, шыгрым, исәр, ара, тал, Мягков, бу, Заһитов, ау.

Беләсең килсә...

1 Манарадагы иң борынгы сәгать кайда урнашкан?
а) Мисырда;
б) Кытайда;
в) Англиядә.

2 Муса Бигиевне дөньяда нинди исем белән беләләр?
а) Муса Ярулла;
б) Муса Джарулла;
в) Муса Хәйрулла.

3 Ризотто ризыгы нәрсәдән ясала?
а) бәрәңгедән;
б) дөгедән;
в) токмачтан.

4 Казанда 1, 2, 3, 4, 5 нче номерлы нинди урам бар?
а) Муром урамы;
б) Курск урамы;
в) Смоленск урамы.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. б); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакулам коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының уәзк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 320

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+